ШИМБӘ
6 АПРЕЛЬ
1940 ел
№ 80 (5880)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик һәм культура бүлекләре 18—22, авыл хуҗалыгы бүлеге 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, информация һәм совет төзелеше бүлекләре 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ҖИТӘКЧЕ КАДРЛАРНЫ МАРКСИЗМ-ЛЕНИНИЗМ ТЕОРИЯСЕ БЕЛӘН КОРАЛЛАНДЫРЫЙК

Партиянең башлангыч оешмаларында булып үткән отчет-сайлау җыелышлары һәм ВКП(б) ның район, шәһәр һәм өлкә конференцияләре партия пропагандасы мәсьәләләренә, партия члeннарын идея-политик актан тәрбияләү мәсьәләләренә бик нык әһәмият бирделәр. Бу өлкәдә тупланган бай тәҗрибәләргә йомгак ясадылар, хәзерге вакытта яшәп килә торган кимчелекләрне кискен тәнкыйтьләделәр һәм киләчәк өчен конкрет чаралар билгеләп калдырдылар.

Партияле һәм партиясез кадрларыбызны дөньяда иң революцион теория белән, марксизм-ленинизм теориясе белән, ягъни иҗтимагый үсеш һәм политик көрәш законнары белән коралландыру эшендә соңгы ел ярым вакыт эчендә күп нәрсә эшләнде.

Хәзерге вакытта „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н урта буын буенча өйрәнүне тәмам итеп марксизм-ленинизм классикларының аерым әсәрләрен өйрәнергә керешкән иптәшләр аз түгел. Шулай ук күп кенә иптәшләр „Кыскача курс“ ның VIII, IX нчы бүлекләрен, Маркс, Энгельс, Ленин, Сталинның аерым әсәрләрен өйрәнәләр, газета - журналларда басылган теоретик мәкаләләрне, консультацияләрне, лекцияләрне регуляр рәвештә укып баралар. Мондый иптәшләр өчен үзләренең идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү буенча системалы рәвештә эшләү гадәт булып әверелде. Мондый иптәшләр социализм төзү эшенең көндәлек практикасында үзләрен көчле хис итәләр, бик тиз үсәләр, төрле җаваплы эшләргә күтәреләләр һәм анда үзләрен аклыйлар.

Мисаль өчен, Казандагы Кинопленка фабрикасында эшләүче инженерларыннан Толстов һәм Мужиев иптәшләрне алыйк. Бу иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н урта буын буенча өйрәнеп, хәзерге вакытта марксизм-ленинизм классикларының әсәрләрен өйрәнәләр. ВКП(б) ның Ленин райкомы аларны үзенең лекторлары итеп билгеләгән. Иптәш Толстов ВКП(б) тарихы буенча, ә иптәш Мужиев [illegible] буенча районда лекцияләр укыйлар. Бу иптәшләр фабрикаларында үзләре дә агитация-пропаганда эшләрендә актив катнашалар. Партия тарихын үзләштергән өйрәнүче иптәшләргә ярдәм итәләр, беседалар, консультацияләр үткәрәләр, докладлар ясыйлар, лекцияләр сөйлиләр. Мондый мисалларны бик күп китерергә мөмкин.

Ләкин, җитәкче кадрларыбызның бер өлеше үзенең идея-политик һәм теоретик белемен күтәрү өстендә җитәрлек эшләми әле. „Кыскача курс“ басылып чыгуга ел ярым вакыт үтүгә карамастан, беренче өйрәнүне булдыра алмаучы иптәшләр дә юк түгел әле. Гадәттә мондый иптәшләр үзләренең укымауларына сәбәп итеп „вакыт җитмәү“не күрсәтәләр, ләкин бу сылтау гына. „Эш белән мавыгучы“ мондый иптәшләр практик эшләрне дә артта сөйрәлеп баралар.

Мисаль өчен Татсоюз председателе иптәш Осипцевны алыйк. Ул үзенең идея-политик дәрәҗәсен күтәрү өстендә һич тә канәгатьләнерлек эшләми, ел ярым вакыт эчендә „Кыскача курс“ның бары тик [illegible] бүлеген генә өйрәнгән. Башка [illegible] кебек, иптәш Осипцев та сылтау итеп „вакыт юклыкны“ ала. Ләкин бу сәбәп түгел, ә бары тик сылтау гына. Иптәш Осипцев җитәкчелек итә торган оешмаларның [illegible] эшендә җитди кимчелекләр [illegible]. Иптәш Осипцев үзенең политик һәм теоретик белемен күтәрү өстендә ныклап эшләсә, бу кимчелекләр күп тапкырларга ким булган булырлар иде. Педагогия институты директоры иптәш Садыйков белән дә эшләр шулай тора. Ул да үзенең идея-политик дәрәҗәсен күтәрү буенча начар эшли. Шуның өчен дә институтның көндәлек практик эшендә күп кенә җидди кимчелекләр бар. Мәсәлән, студентлар арасында политик тәрбия эшләре тиешле дәрәҗәдә түгел, уку дисциплинасын бозу фактлары еш кына була, аерым студентлар арасында эчүчелек фактлары да бар.

Коммуналь хуҗалыгы наркомы Сорвин, Татарстан Верховный Суды председателе Шәмсеттинов, Энергокомбинат директоры Никитин, Нархозучет җитәкче работникларыннан берсе Кадыйров, Тирсә машина-трактор станциясе директоры Гайнуллин иптәшләр дә үзләренең теоретик һәм политик артталыкларын бетерү өстендә начар эшлиләр. „Шуны аксиома итеп танырга кирәк ки, дәүләт һәм партия эшенең һәрбер тармагында работникларның политик дәрәҗәсе һәм марксистик-ленинчел аңлылыгы никадәр югары булса, эш тә шул кадәр югары һәм уңышлы, эшнең нәтиҗәләре шул кадәр эффектлы була, һәм киресенчә,—работникларның политик дәрәҗәсе һәм марксистик-ленинчел аңлылыгы никадәр түбән булса, эштә өзеклекләр һәм проваллар шул кадәр ихтималрак, работникларның үзләренең вакланулары һәм тар карашлы вакчыл кешеләргә әйләнүләре шул кадәр ихтималрак, аларның перерожденец булулары шул кадәр ихтималрак“ (Сталин). Юлбашчының бу күрсәтмәләрен безнең работникларыбыз бер генә минутка да хәтерләреннән чыгармаска тиешләр.

Кадрларны марксизм-ленинизм теориясе белән коралландыру эше партия оешмалары җитәкчеләренең [illegible] күрсәтүгә бик нык бәйләнгән. Партия оешмасы секретаре пропаганда эшләренә турыдан-туры үзе җитәкчелек итәргә тиеш, [illegible]. Шулай булмаганда ул кадрларның үзләренең идея-политик дәрәҗәләрен ничек күтәрүләрен контрольдә тота алмый, аларга конкрет ярдәм дә күрсәтә алмый.

ВКП(б) ның Минзәлә райкомы секретаре иптәш Хәкимҗанов үзенең идея-политик белемен күтәрү өстендә системалы рәвештә эшли, башкаларга үрнәк күрсәтә, пропаганда эшләрендә конкрет җитәкчелек итә. Иптәш Хакимҗанов районның җитәкче кадрларының [illegible] күтәрү өстендә эшләүләрен күзәтә, кирәк вакытта контрольлек итә һәм аларга конкрет ярдәм күрсәтә, ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләр белән системалы рәвештә беседалар [illegible] үткәрә.

Биләр, Баулы, Бондюг районнарында күп кенә коммунистлар һәм партиясез җитәкче работниклар теоретик һәм политик артталыкларын бетерү өстендә бөтенләй диярлек эшләмиләр. Җитәкче кадрларыбызның бер өлешенең идея-политик үсешенә игътибар итмәү [illegible], хәзерге көндә пропаганда эшендәге иң җитди кимчелекләрнең берсе.

Үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә эшләмәүче җитәкче кадрларга [illegible] тиешле [illegible] итәргә тиешбез. [illegible] пропаганда эшендәге бу кимчелекләрне бик тиз бетерергә кирәк.

СССР ның I нче чакырылыш Верховный Советының Алтынчы Сессиясендә Союз Советының 1940 ның ел, 1 нче апрельдә булган утырышында. Рәсемдә: делегатларыдан бер төркем Кремль Зур Сараеның Георгиевский залында тәнәфес вакытында. Сулдан уңга: Е. М. Кожушана (Енницкий өлкәсе), М. А. Перепелица (Львов өлкәсе), М. Н. Яковюк (Волынский өлкәсе) һәм И. П. Ларионов (Мордовия АССР дан).

А. Гриборский фотосы (ТАСС фото-клишесе).

СОЮЗ СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ҺӘМ МИЛЛӘТЛӘР СОВЕТЫ УТЫРЫШЫ ТУРЫНДА ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

4 апрель, 1940 ел

4 нче апрельдә, көндез 11 сәгатьтә, Кремльдә, СССР Верховный Советының утырышлар залында, Союз Советының бишенче утырышы, кич 6 сәгатьтә—Милләтләр Советының бишенче утырышы булды.

Союз Советы утырышында—Союз Советы Председателе депутат **А. А. Андреев**, Милләтләр Советы утырышында—Милләтләр Советы Председателе депутат **Н. М. Шверник** председательлек итәләр.

Ике палатаның утырышларында да СССР Халык Комиссарлары Советы керткән закон проектлары каралды.

Союз Советы һәм Милләтләр Советы „Халыктан доход налогы турындагы закон“ны, „Доход налогы салына торган халыктан торак һәм культура-көнкүреш төзелеше кирәкләренә җыем турындагы закон“ны һәм „Мәҗбүри окладной страхование турындагы закон“ны статьялап уку тәртибендә башта статьялап, аннары тулы килеш бер тавыштан расладылар.

Аннары Союз Советы һәм Милләтләр Советы Сессиянең көн тәртибенең дүртенче мәсьәләсен—СССР Верховный Советы Президиумының сессияләр арасындагы чорда кабул ителгән һәм СССР Верховный Советы расларга тиеш булган указлары турындагы мәсьәләне карады.

Бу мәсьәлә буенча докладны ике палатада да СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре депутат **А. Ф. Горкин** ясады.

Союз Советы һәм Милләтләр Советы Төркмәнстан ССР да, Таҗикстан ССР да һәм Кыргызстан ССР да өлкәләр төзелү, Украина ССР да, Белоруссия ССР да һәм Казагстан ССР да яңа өлкәләр төзелү уңае белән, Пермь өлкәсенең исмен Молотов өлкәсе дип үзгәртү һәм Карелия АССР ны Союзный Карел-Фин Совет Социалистик Республикасы итеп төзү уңае белән, СССР гомуми Союз күләмендәге Ягулык Промышленносте Халык Комиссариатын ике комиссариатка—Күмер Промышленносте һәм Нефть Промышленносте Халык Комиссариатларына бүлү уңае белән СССР Конституциясенә (Төп Законга) 29-а һәм 29-б статьяләре өстәү һәм аның 22, 23, 27, 28, 29 һәм 77 нче статьяләрен үзгәртү һәм аларга өстәмәләр кертү турындагы законны бер тавыштан раслыйлар.

Шулай ук ике палата да СССР Верховный Советы Президиумының „Украина Совет Социалистик Республикасы белән Белоруссия Совет Социалистик Республикасы арасында өлкәләрне чикләү турында“гы указын һәм СССР Верховный Советының түбәндәге иптәшләрне билгеләү турындагы указларын бер тавыштан раслый:

Төзелеш Халык Комиссары итеп иптәш **С. З. Гинзбургны**,

СССР ның Сәламәтлек Саклау Халык Комиссары итеп иптәш **Г. А. Митеревны**,

СССР ның Нефть Промышленносте Халык Комиссары итеп иптәш **Л. М. Кагановичны**,

СССР ның Күмер Промышленносте Халык Комиссары итеп иптәш **В. В. Вахрушевны**,

СССР ның Авиация Промышленносте Халык Комиссары итеп иптәш **А. И. Шахуринны**,

СССР Совнаркомы янындагы Сәнгать Эшләре Комитетының Председателе итеп иптәш **М. Б. Храпченконы**,

Хәзерләүләр Халык Комиссары итеп иптәш **В. А. Донскойны**.

Шуның белән СССР Верховный Советының Алтынчы Сессиясе үзенең эшен тәмам итә.

Редакциядән

„Кызыл Татарстан“ газетасының 30 нчы мартта чыккан номерында урнаштырылган „Колхозларда эш атларыннан файдалану турында“ (ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросында) дигән материалның икенче баганасындагы беренче абзацны түбәндәгечә укырга кирәк: „Бригадаларны шушы елның 10 нчы апреленнән дә соңга калмыйча тикшерелгән ат караучылар составы белән комплектлаштырырга, аларга атларны беркетергә һәм ат караучыларга хезмәт хакы түләү эшен атларны тәрбияләү турындагы инструкция нигезендә оештырырга кирәк“.

КЫР ЭШЛӘРЕ БАШЛАНДЫ

Минзәлә районының күп кенә колхозларында 5 нче апрельдә язгы кыр эшләре башланды. Иске Александровка авыл советына караган „Свобода“, „Волна“ һәм „Красный Курган“ колхозлары туңга сөрелгән җирләрне тырмалау эшенә керештеләр. Яңа Маҗын авыл советының „Победа“ колхозы беренче 10 гектарга солы чәчте. „1 Мая“ колхозында 20 гектар җиргә клевер чәчелде.

6 нчы апрельдә Батрак авыл советында трактор бригадасы кыр эшләренә керешә. (ТатТАСС).

Колхоз правлениесенең эшлексезлеге турында

ӘЛМӘТ, 5 апрель. (**Телефон буенча**). Без колхозның беренче бригадасының 2 нче звено җитәкчесе иптәш **Хәкимә Тагиевадан**:

— Синең звеноң хәзер нәрсә эшли, язгы чәчүдә агротехника чаралары планы бармы, дип сорадык.

Ул бу сорауга:

— Мин әле үземнең звено җитәкчесе итеп билгеләнгәнемне дә белмим, дип җавап бирде.

Әлмәт авылы Сталин исемендәге колхозда бу очраклы хәл түгел. 5 нче бригаданың звено җитәкчесе иптәш Гәрәеваны хәзер хат йөртүче итеп куйганнар. Шунлыктан звеноларның берсе дә конкрет эшкә керешмәгән, чөнки звеноларга колхоз председателе иптәш Вәлиев тә, бригадирлар да җитәкчелек итмиләр. Бригадаларда колхозчылар аерым эш тармакларына беркетелмәгәннәр.

Ул гына да түгел. Беренче бригада бригадиры иптәш Гыйбадуллин да бригадасының үз көче һәм тракторлар белән күпме эш башкарачагын белми. Колхоз правлениесе өчен гүяки бригадалар да, колхозчылар да юк.

Чәчү орлыгы хәзерләү һәм аны тазарту бик начар тора. Колхозда 150 центнер солы җитешми. Шул ук вакытта колхозның үзенә җитешмәгән солы орлыгына алыштырып алырга мөмкин булган 50 центнер борчакны су астында калдырып әрәм иткәннәр. 375 центнер бодай, 430 центнер солы орлыгы чистартылмаган. Чәчү орлыкларын яровойлаштыру өчен урын һәм кешеләр билгеләнмәгән. Термик агулау эше башланмаган. Орлыклар бик начар саклана. Солы орлыгына түбәдән су үтә. Амбар тирәләре чистартылмаган.

Колхозда атлар ялга куелган, ләкин алар аерым караучылар җаваплылыгына беркетелмәгәннәр. Атларны тәрбияләү эше һич канәгатьләнерлек түгел. Атларга башак бирү өчен улаклар юк. Ат сбруйлары җитәрлек түгел. 5 нче бригадада 25 баш атка 12 арба, 2 нче бригадада 28атка бары 6 арба бар. Аларына да ремонт ясалмаган. Өченче бригадада камыт һәм пастромка баулары җитми. Кыскасы, колхоз язгы чәчүгә хәзер түгел әле.

Без рейд вактында әнә шундый картинага очрадык. Рейд бригадасы тарафыннан ачылган кимчелекләр колхоз активы җыелышында тикшерелде. Язгы чәчүгә хәзерлектә булган кимчелекләрне ашыгыч бетерү өчен тиешле чаралар билгеләнде. Рейд бригадасы ярдәме белән стена газеталары чыгарылды.

Рейд бригадасы члeннары
Банат Гайнуллина,
Гомәр Хәниев,
Сабир Зәйнуллин,
Гаян Бикәева.

Шөгердә чәчүгә хәзерлек кайчан тәмам булыр?

ШӨГЕР, 5 нче апрель. (**Телефон буенча**). Шөгер районында артта калып баручы колхозлар турында сүз чыга калса, беренче итеп „Пролетарий“ колхозын телгә алалар. Бу моннан 3 ел элек тә шулай иде. Үткән ел да шулай булды, быел да шулай ук. Үткән елда биредә язгы чәчүнең барлык сроклары өзелде. Бу башлыча аны хәзерлексез каршылаудан килеп чыкты. Ләкин бу хәл колхоз правлениесен дә, район оешмаларын да борчымаган. Алар моннан кирәкле нәтиҗәләрне ясамаганнар. Бу колхозда язгы чәчүгә хәзерлек эше быел да җинаятле рәвештә өзелә. Хәзергә кадәр орлык туплау эше төгәлләнмәгән. 200 центнер бодай, 60 центнер вика орлыгы җитешми. Булган орлыклар да тиешле кондициягә җиткерелмәгән. Кондициягә җиткерелгән бары 118 центнер солы орлыгы бар. Орлыкларның сакланышы начар. Орлыклар амбарларга гадәттән тыш калын итеп салынганнар. Мәсәлән, бодай һәм борчак орлыклары амбар түбәсенә кадәр җиткерелгән, ә түбәдән су үтә. Карабодай орлыгын кулга алып сыксаң су чыга. Орлык агулау һәм яровойлаштыруга бер төрле дә хәзерлек юк. Агулау өчен савыт-саба, урын, термик агулау өчен термометр—берсе дә хәзерләнмәгән. 59 килограмм формалин, 40 килограмм Давыдов препараты Сельхозснабтан алып кайтылмаган. Колхозның агротехнигы иптәш Константинов бу чараларны үткәрүдә үзендә җаваплылык сизми. Колхозда язгы чәчүгә хәзерлекнең башка тармаклары да шундый ук начар хәлдә. Без, башкаларга тукталып тормыйча, эш планнарының да колхозчыларга җиткерелмәвен әйтү белән чикләнәбез. Монда район оешмаларыннан күп кенә вәкилләр булган. Ләкин алар колхозны бу хәлдән чыгару өчен тиешле чараларны күрмәгәннәр.

Орлыкларны агулау һәм язга хәзерлек эшенә гомумән районда әһәмият бирелми. Район колхозлары Сельхозснабтан әле һаман да химикатларны алып җиткермәгәннәр. Давыдов препараты 40 колхозга кирәк, ә бары 10 гына колхоз алган. Шөгер МТС ы бу препаратларны кайсы колхозга күпме бирү турында Сельхозснабка наряд бирмәгән әле. Шунлыктан күп кенә колхозлар кирәкле препаратларны ала алмый торалар. Районга кирәкле булган 370 банк нефилиннан бары 20 банк кына алынган. Бу фактлар Шөгер районында язга хәзерлекнең йомшак булуын күрсәтәләр һәм район оешмаларыннан бу җитешсезлекләрне бик тизлек белән бетерү чараларын таләп итәләр.

Рейд бригадасы члeннары
И. Хәйреттинов,
М. Салманова,
М. Хәмидуллин.

Җитешсезлекләрне бетерү чаралары күрелә

НОРЛАТ, 5 апрель. (**Махсус хәбәрчебездән телеграф буенча**). Без, эшче-авыл хәбәрчеләренең рейд бригадасы члeннары Нәриман исемендәге колхозның язгы чәчүгә хәзерлеген тикшердек.

Тикшерү нәтиҗәсендә язгы чәчүгә хәзерлек эшендә күп кенә җитешсезлекләр булуы беленде. 12 центнер тары чәчүгә яраклы түгел. Атларга азык өчен хәзерләнгән 65 центнер он түбәдән су үтеп бозылган. 150 центнер печән һәм 350 центнер салам кырда ташылмый калган.

Шулай ук машиналарны һәм инвентарьларны ремонтлау эше дә бик начар тора. 31 сабан әле дә ремонтланмаган, 3 нче бригаданың тырмалары кар астында калган булган. Аларны кар эрегәч кенә табып алдылар. Колхоз җитәкчеләре язгы чәчүгә хәзерлек эшенә начар җитәкчелек итәләр. Алар күбрәк канцеляриядә утырып гомер үткәрәләр.

Атларны тәрбияләү эшенә дә әһәмият бирелми. Аларның күпчелеге бик түбән көрлектә.

Иптәш Шакиров җитәкчелек итә торган 5 нче бригадада хезмәтне оештыру буенча күп кенә уңышлы тәҗрибәләр дә бар. Эш планы һәм нормалар бригада члeннарына җиткерелгән. Алар үзара ярышып эшлиләр. Ләкин колхоз җитәкчеләре бу бригаданың уңышлы тәҗрибәләрен башкаларга күчерү белән шөгыльләнмиләр.

Рейд бригадасының тикшерү нәтиҗәсе колхозның партия, комсомол активы җыелышында һәм бригадалар җыелышларында тикшерелде, шулай ук стена газеталарында яктыртылды.

Хәзер тикшерү нәтиҗәсендә ачылган җитешсезлекләрне бетерү буенча конкрет чаралар күрелә. Без бу эштә колхоз правлениесенә һәм бригадаларга булышлык күрсәтәбез.

Бригада члeннары
Җаббаров, Әнлиуллин,
Туктамышев, Садыйков,
Әхметов.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

СССР БЕЛӘН ИРАН АРАСЫНДА СӘҮДӘ ҺӘМ ДИҢГЕЗ ЮЛЫ ТУРЫНДАГЫ ДОГОВОРНЫ РАТИФИКАЦИЯЛӘҮ

ТАҺРАН, 5 апрель, (ТАСС). Бүген Иран мәҗлесе шушы елның 25 нче мартында СССР белән Иран арасында сәүдә һәм диңгез юлы турында төзелгән договорны бер тавыштан ратификацияләде.

ТӨРКИЯНЕҢ ОБОРОНА МИНИСТРЕНЕҢ ОТСТАВКАГА ЧЫГУЫ

АНКАРА, 5 апрель. (ТАСС). Анатолий агентлыгының хәбәр итүенә караганда, милли оборона министре Наджи Тынас отставкага чыккан. Оборона министре постына Эрзинҗаннан мәҗлес депутаты, элекке мәгариф министре һәм халык-республика партиясенең элекке генераль секретаре Саффет Арыкан билгеләнгән.

СССР ның I нче чакырылыш Верховный Советының Алтынчы Сессиясе

Депутат В. К. ТРУТНЕВ рече

(ТАССР НЫҢ КАЗАН АВЫЛ ОКРУГЫ)

Депутат иптәшләр! Советлар Союзы хөкүмәте Ватаныбызның 1940 нчы елгы бюджетын тикшерү һәм раслау өчен Верховный Советның Алтынчы Сессиясенә кертте.

Элек чыгып сөйләгән депутат иптәшләр белән берлектә мин Халык Комиссарлары Советы тарафыннан кабул ителгән бюджетны Верховный Совет раслар дип ышаныч белдерәм.

1940 нчы елгы бюджет бөтен халык хуҗалыгының өзлексез үсү процессын чагылдыра. Бу бюджет күп миллионлы совет халкының иҗат эшенең нәтиҗәләрен чагылдыра. Бюджетның һәрбер бүлеге җиңүле рәвештә үтелгән юлның шаһите һәм бюджетның һәрбер саны безгә, совет кешеләренә чиксез кадерле һәм аңлаешлы.

1940 нчы елгы бюджетның гаять зур күләмдә булуы Советлар иленең бөек куәтен күрсәтә һәм һәрбер совет гражданины үзенең социалистик Ватанының бу куәте белән горурлана. Без илебезгә коммунистик партия һәм бөек Сталин җитәкчелек итүе белән бәхетле һәм горур.

Бөтен халык хуҗалыгын, дәүләтне социал-культура һәм оборона төзелешен тәэмин итү өчен илебезнең җитәрлек санда гаять зур эчке ресурслары бар.

Безнең дәүләт бюджеты—ул, халык байлыгының тагын да чәчәк атуы һәм өзлексез үсүе бюджеты. Ул кеше турында Сталинча кайгыртучанлык белән сугарылган. Бу кайгыртучанлык халык хуҗалыгын тагын да үстерү өчен җибәрелә торган средстволарның артуында күренә; бу кайгыртучанлык илнең оборона ихтиаҗларына ассигнованиене арттыруда чагылдырылган, чөнки Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының куәтен өзлексез көчәйтү—совет халкының иректе хезмәтенең һәм бәхетле тормышының иң ышанычлы гарантиясе, ниһаять, бу кайгыртучанлык, социал-культура чаралары бүлеге буенча мәгариф эшенә, сәламәтлек саклау һәм социал-тәэминат эшенә средстволарны арттыруда күренә.

Мин, бюджетның сәламәтлек саклауга һәм физкультурага кагылган расходлары өлешенә тукталырга телим. Сәламәтлек саклауга һәм физкультурага тотыла торган расходлар сумасы 10 миллиард сумга җитә. Бу сан илебездә хезмәт ияләренең сәламәтлеген саклау эшенең нинди югарылыкка күтәрелгәнлеген күрсәтә.

Һәр кемгә билгеле, патша Россиясе үлүчеләр иң күп булган ил иде, төрле төстәге авырулар иле иде. Әгәр хәзерге вакыттагы үлүчеләрнең гомуми санын 1913 нче елда үлүчеләр саны белән чагыштырсаң, ул ике тапкырдан артык кимегән булып чыга.

Трахома кебек авыруларның таралуы шактый кимеде, трахома авыруы гаять зур социал бәхетсезлекләргә китерә иде.

Бары тик Совет Социалистик Республикалар Союзында гына күп балалы аналарга дәүләт пособиеләре бирелә. Безнең 182 миллиард сумлык бюджетыбыз бу пособиеләрнең күләмен 1 миллиард 162 миллион сумга кадәр җиткерү мөмкинлеген бирә.

Совет Социалистик Республикалар Союзы үзенең аналар турында һәм балалар турында Сталинча кайгыртучанлыкны чагылдыра торган чаралары белән горурлана ала. 1940 нчы елгы бюджет шәһәрләрдә, район үзәкләрендә, эшчеләр поселкыларын да бала тудыру эшен яхшы оештыруны тулысынча тәэмин итә һәм акушерлык ярдәмен авыл халкына якынайта.

Советлар Союзы халыклары яслеләр челтәрен 1940 нчы елгы планда күздә тотылганча тагын да арттыруны һәм киңәйтүне зур канәгатьләнү белән каршы алырлар. Бу план буенча 900 мең бала һәр вакыт эшләүче яслеләр белән тәэмин ителәчәк һәм 4 миллионга якын бала кыр эшләре вактында төзелә торган яслеләрдә тәрбияләнәчәк.

Совет власте төзелгән вакытта Россиядә бары 20 мең врач бар иде. Хәзер Совет Социалистик Республикалар Союзында врачларның 120 меңлек армиясе бар, алар үзләренең көчләрен һәм белемнәрен хезмәт ияләре бәхтенә бирәләр, алар Ерак Көнчыгышта, Көнбатыш Белоруссия һәм Көнбатыш Украина кырларында һәм ак финнәргә каршы сугышларда үзләренең гражданлык бурычларын намус белән үтәделәр.

Узган 1939 нчы ел Көнбатыш Белоруссиядәге һәм Көнбатыш Украинадагы кардәш халыкларны паннар изүеннән азат итүнең тарихи акты белән истә калды. Сәламәтлек саклау бүлеге буенча бюджетның үсүе Украина һәм Белоруссия ССР ның көнбатыш өлкәләрендә медицина-санитария челтәрен оештыру белән бәйле булган расходларны да күздә тота. Бу өлкәләрдә Совет власте яшәгән кыска гына срок эчендә халыкка квалификацияле медицина ярдәме күрсәтү оештырылды инде.

1940 нчы елгы бюджетта Украина һәм Белоруссия Совет Социалистик Республикаларының көнбатыш өлкәләре өчен гаять зур санда больница һәм бала тудыру койкаларын арттыру һәм киңәйтү күздә тотыла. Хезмәт ияләренә хезмәт күрсәтү өчен бу өлкәләрдә курортлар челтәре киң күләмдә ачылды.

Советлар Союзы—хезмәт ияләренең сәламәтлеген тиңдәшсез югарылыкка күтәрергә омтылып, дәүләт сәламәтлек саклау эшен төзүче бердәнбер ил.

Депутат иптәшләр! Без дөньяда бердән-бер илнең вәкилләре, бу илдә фән партия һәм хөкүмәт тарафыннан һич кайчан күрелмәгәнчә игтибар һәм тиңдәшсез кайгыртучанлык белән чолгап алынган. Безнең фәнебез үзенең тирән эчтәлеге белән бай, инициатива кыюлыгы белән, фикерләр кыюлыгы белән бай, техник җиһазлар, яхшы җиһазландырылган кабинетлар һәм лабораторияләр белән бай.

Авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсендә академик Цицинга иптәш Сталин „кыю рәвештә эксперимент ясагыз, без сезгә ярдәм итәрбез“ диде. Юлбашчыбызның бу сүзләре фәнебезнең чәчәк атуы өчен көрәшүче барлык алдынгы галимнәргә һәм белгечләргә кагыла.

Советлар Союзында фәнни работниклар үзләренең барлык көчләрен, барлык иҗадларын, барлык инициативаларын кешелек дөньясының бөек даһилары Ленин һәм Сталин тарафыннан туры һәм ачык итеп күрсәтелгән нигезләрдә коммунистик җәмгыять төзү эшенә бирәләр.

Социалистик төзелеш геройларны тудыра, энтузиазм һәм пафос тудыра, шатлык, кыюлык һәм тормышка омтылучанлык урнаштыра. Безнең социалистик илнең сәламәтлек саклау эше, безнең совет медицина фәне шушы тормышка, Сталин эпохасының шушы чәчәк атучы кешесенә хезмәт итәргә тиеш, ул бөтен дөньяда медицина фәненең авангарды булып әверелергә тиеш. Бу соңгы максатка иң якын срок эчендә ирешүне тәэмин итү өчен сәламәтлек саклау органнары фәнни тикшерену эшен оештыру буенча күп эшләргә тиешләр. Сәламәтлек саклау органнары фәнни-тикшерену эшен дәвалау һәм санитария-профилактика эше практикасына гаять зур кыюлык белән бәйләргә тиешләр. Тикшерену учреждениеләренең работниклары дәвалау һәм теге яки бу потологик процесс белән какшаган сәламәтлекне яхшырту буенча яңа һәм аеруча лаеклы средстволар һәм методлар эзләп табуга зур игтибар бирергә тиешләр.

Ләкин бу юнәлештә инде күп нәрсәләр эшләгән сәламәтлек саклау работниклары, үзләрендә булган барлык мөмкинлекләрдән файдаланмадылар һәм социалистик җәмгыять куйган таләпләрне әле тулысы белән үтәмәделәр.

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе турында кайгыртучанлык күрсәтү—ул, ирекле һәм тыныч хезмәт турында кайгыртучанлык күрсәтү дигән сүз. Безнең Кызыл Армиябез тыныч хезмәтнең ышанычлы терәге генә түгел, бәлки ул зур мәктәп тә. Кызыл Армиянең куәтен арттыру белән без, халкыбызның культура үсешен арттырабыз һәм яшьләребезне тәрбиялибез, алар армиядә мораль һәм физик чыныгу алалар.

Кызыл Армиягә һәм Хәрби Диңгез Флотына ассигнованиене арттыру турында хөкүмәтнең тәкдимен без гаять зур рухлану һәм энтузиазм белән каршы алабыз, чөнки бу безнең тыныч хезмәтебезне, чикләребезнең саклануын, аталарыбызның картлык көннәренең тынычлыгын, улларыбызның һәм кызларыбызның шатлыклы балалык һәм яшьлек вакытларын тәэмин итә.

Депутат иптәшләр! Сәламәтлек саклау органнары эшендәге кайбер җитешсезлекләргә тукталырга рөхсәт итегез.

Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты халыкка медицина хезмәте күрсәтүнең сыйфатын күтәрү өчен көрәшкә барлык медицина работникларын туплый алмады. Медицина учреждениеләребезнең көче тулысынча файдаланылмады.

Урыннардагы партия һәм совет органнарының күпчелеге Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариатына актив ярдәм иттеләр һәм ярдәм итәләр; ләкин шул ук вакытта, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советлары тарафыннан сәламәтлек саклау мәсьәләләренә җитәрлек игтибар бирелмәү фактлары да очрый.

Сәламәтлек саклау органнарына партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан күрсәтелә торган игтибар бу җитешсезлекләрнең иң якын араларда бетереләчәгенә гарантия була ала.

Депутат иптәшләр! Халык хуҗалыгы планына туры китереп төзелгән һәм ул планны тормышка ашыруны тәэмин итә торган 1940 нчы елгы бюджет, героик коммунистик партия тарафыннан һәм бөек Сталин тарафыннан даһиларча җитәкчелек ителә торган бөек Ватаныбызның тагын да чәчәк атуы өчен гүзәл перспективалар ача. (Кул чабулар).

Матбугат күзәтү урнында

РАЙОННЫҢ ТОТАШТАН ГРАМОТАЛЫ БУЛУЫ ӨЧЕН

Зурлар арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү мәсьәләсенә безнең партиябез һәм хөкүмәтебез гаять зур игтибар бирәләр. Бу эшкә дәүләт бюджетыннан һәр елны күп миллион сумнар акча тотыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, илебездә грамоталы кешеләрнең саны елдан-ел үсә, ә укый-яза белмәүчелек кими бара.

Без аны үзебезнең Татарстан республикасы мисалендә дә ачык күрәбез. Әгәр дә 1939 нчы елның январена Татарстанда укый-яза белмәүчеләр 127 мең 603 кеше саналса, 1940 нчы елның беренче январена бу сан 73 мең 425 кә калды. Ләкин бу безне һич тә тынычландыра алмый. Татарстанның тоташтан грамоталы республика булып әверелүенә ирешү өчен большевикларча көрәшергә тиешбез.

Зурлар арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү мәсьәләсендә район газеталарына да зур җаваплылык йөкләнә. Алар зурларны укыту эшләренең торышын системалы рәвештә яктыртырга, укый-яза белмәүчелекне бетерү мәсьәләсе тирәсенә барлык совет җәмагатчелегенең фикрен тупларга, партия, совет оешмаларына, халык мәгарифе органнарына җидди рәвештә булышырга тиешләр.

Бу мәсьәләдә үзләренең бурычларын дөрес аңлаган газеталар шулай эшлиләр дә. Мисаль өчен ВКП(б) ның Красный Бор райкомы һәм хезмәт ияләре депутатларының район советы органы „Колхоз ярышы“ газетасын (җаваплы редакторы иптәш **Махдумов**) алырга мөмкин. Бу газета, зурларны укыту турында бигрәк тә хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлау кампаниясе чорында ныклы эш алып барды. „Зурларны укыту эшен большевикларча оештырырга“ дигән баш мәкаләсендә (1939 нчы ел 30 нчы октябрь) газета әле бу эшнең районда канәгатьләнерлек оештырылмавын күрсәтеп, район мәгариф бүлеген каты рәвештә тәнкыйть итте. Шул ук мәкаләдә газета: „Хәзер кичекмәстән һәрбер авыл советы һәм район мәгариф бүлеге бу эшне тиешле югарылыкка кую өчен культармеецлар сайлап алу, укыту өчен бинaлар билгеләү, мәктәпләрне дәреслекләр белән, язу әсбаплары һәм ягу-яктырту материаллары белән тәэмин итү эшен оештырырга тиешләр“ дип язды.

Зурларны укыту эшенең торышы турында газета әледән-әле материаллар урнаштырып бара. Мәсәлән, 1 нче январьдан алып 15 нче мартка кадәр булган вакыт эчендә газета бу турыда 7 материал һәм тагын бер баш мәкалә урнаштырды. Газета зурларны укыту эшен начар оештыручыларны тәнкыйтьләү белән генә чикләнми. Бу эшне яхшы оештыручыларны, зурларны укыту эшен намус белән башкаручы алдынгы укытучыларны һәм культармеецләрне да күрсәтергә тырыша. 1940 нчы елның январь номерында газета болай дип язды: „Ямурза авылында культармеец булып эшләүче иптәш Муллаҗан Әхмәдиев яхшы инициатива күрсәтә. Иптәш Муллаҗан 10 иптәшне яхшы укый-яза белүчеләр итеп чыгарды. Бу иптәшләр сынау комиссиясеннән үзләренең укый-яза белүчеләр булып чыгулары турында таныклыклар алдылар...“.

Шулай эшләве белән „Колхоз ярышы“ газетасы районда укый-яза белмәүчелекне бетерү мәсьәләсендә партия, совет оешмаларына һәм халык мәгарифе работникларына зур булышлык күрсәтә. Районның 15 авыл советы буенча укый-яза белмәүчелек бетерелеп, аларга дәүләт актысы тапшырылды. Хәзерге вакытта күп кенә авыл советлары зурларны укыту эшләрен яхшы алып баралар. Менә бу уңышлар Красный Бор районының партия, совет оешмаларының һәм район газетасының бердәм рәвештә көрәшүләренең нәтиҗәләре булып торалар.

Ләкин моның белән укый-яза белмәүчеләрне укыту мәсьәләсен яктыртуда „Колхоз ярышы“ газетасының җитешсез яклары юк дигән нәтиҗәне ясарга ярамый. Зурларны укыту эшен яхшыртуда бу газетаның кимчелекләре дә бар әле. Ул кимчелекләр, барыннан да бигрәк, укый-яза белмәүчеләрне укыту эшләренең торышы турында газетада урнаштырылган хәбәрләрнең күбесенчә өстән-өстән генә язылган булуыннан, аерым авыл советларында зурларны укыту эшләре начар торуының сәбәпләрен тиешенчә ачып салмаудан гыйбарәт. Шулай ук, зурларны укытуны яхшы оештырган авыл советларының, аерым укытучыларның, культармеецләрнең эш тәҗрибәләрен уртаклашуны үзенең битләрендә оештырмавын газетаның зур кимчелеклеге дип санарга кирәк.

„Колхоз ярышы“ газетасы үзенең эшендә булган бу кимчелекләрне кичекмәстән бетерергә тиеш. Ул, зурларны укыту эшләренең торышын тулырак яктырту нигезендә, Татарстанның XX еллыгын тоташтан грамоталы район булып каршылау тирәсенә җәмагатчелек фикрен туплау өчен ныграк көрәшергә тиеш.

АГИТАЦИЯ-МАССА ЭШЛӘРЕН ТИЕШЛЕ ЮГАРЫЛЫККА КҮТӘРИК

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар вактында эпохабызның бөек документы—Сталин Конституциясен, сайлау законнарын, Советлар Союзының тышкы һәм эчке политикасын, партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарларын хезмәт ияләренең киң катлавына аңлату буенча гаять зур эшләр эшләнде. Бу нәрсә—һәрбер предприятие, учреждение, колхоз, совхоз, уку йортлары тәҗрибәсендә бик ачык күренде.

Менә шуларның берсен—Казандагы Кинопленка фабрикасын алыйк. Бу фабрикада партия, комсомол, профсоюз оешмалары сайлаулар вактында агитация-масса эшләрен киң күләмдә оештырдылар. Агитация-масса эшләре фабриканың үзенең эшчеләре, инженер-техниклары, хезмәткәрләре арасында гына түгел, ә фабрикадан тыш та, сайлау участкыларында да нык җәелдерелгән иде. Сайлаулар вактында 120 гә якын кеше агитатор булып, 80 нән артык кеше сайлау комиссияләренең председательләре, секретарьлары, комиссия членнары, доверенныйлар булып эшләделәр. 14 һәм 17 нче сайлау участкыларында сайлау кампаниясе чорында 570 кә якын беседа, 15 доклад, 14 экскурсия оештырылды, берничә тапкыр кино, концертлар күрсәтелде.

Агитаторлар, докладчылар, доверенныйлар сайлаучылар белән һәр көнне диярлек очрашалар иде. Халык аларны көтеп каршы алырга, аңлашылмаган мәсьәләләр булса бергәләп аңлашырга, алар белән киңәшләшергә гадәтләнгән иде. Кыскасы—агитатор сайлаучыларның иң якын киңәшчесе булып киткән иде. Ә бит агитация-масса эшләренең уңышлы үтәлүе өчен, аны тагын да киң җәелдерү өчен бу хәлнең әһәмияте чиксез зур. Партия, комсомол, профсоюз оешмалары моңа игтибар итәргә, сайлау кампаниясе вактында тупланган бай тәҗрибәне ныгытырга тиешләр иде. Ләкин, кызганычка каршы, Кинопленка фабрикасында бу нәрсәгә тиешле игтибар бирелмәгән. Сайлаулар үтү белән элекке сайлау участкыларында агитация-масса эшләре бөтенләй диярлек тукматылган. Хәзерге вакытта элекке участкыларда бары 1—2 генә агитатор үзләренең эшләрен дәвам иттерәләр, алар да системалы эш алып бармыйлар. Элеккеге сайлау участкыларында, бигрәк тә йорт хозяйкалары арасында агитация-масса эшләрен җәелдерүнең әһәмияте турында сөйләп торасы да юк. Хезмәт ияләре халыкара хәл белән, социализм иленең көндәлек бай вакыйгаләре белән чиксез нык кызыксыналар, бу мәсьәләләрдә агитатор аларга турыдан-туры ярдәм итәргә, аларның сорауларына тулы итеп җавап бирергә тиеш. Советлар Союзы үсешнең яңа полосасына — сыйныфсыз социалистик җәмгыять төзүне тәгәлләү һәм социализмнан коммунизмга теземле рәвештә күчү полосасына керде. Бу чорда хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү, кешеләрнең аңында капитализм калдыкларына каршы көрәш хәл иткеч урын алып тора. Хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә агитация-масса эшләре гаять зур урын тота. Шулай булгач, элекке сайлау участкыларында агитация-масса эшләрен сайлаулар үтү белән туктату Кинопленка оешмаларының, беренче чиратта партия оешмасының эшендә булган зур кимчелекләрнең берсе.

Агитация-масса эшләре элекке сайлау участкыларында гына түгел, ә фабриканың үзендә дә сайлау кампаниясе үтү белән сизелерлек йомшарган. Сайлаулар вактында эшләгән 120 агитаторның хәзерге көндә бары тик 80 не генә эшли. Шулай ук, сайлау кампаниясендә актив катнашкан күп кенә иптәшләр (сайлау комиссияләре членнары, председательләре, секретарьлары, доверенныйлар) хәзерге вакытта агитация-масса эшенә тартылмаганнар.

Агитация-масса эшләренең яхшы, яисә начар куелышы агитколлективлар эшенә бик нык бәйләнгән. Агитколлективлар үзләре яхшы эшләгән урыннарда массалар арасында агитация-масса эшләре дә яхшы куелган була. Кинопленка фабрикасында барлыгы 5 агитколлектив бар. Ләкин агитколлективлар алдан билгеләнгән план буенча эшләмиләр. Агитколлективлар өчен семинарзанятиеләре оештырылмаган, тәҗрибәләрне уртаклашу эше практикага кертелмәгән, үткәрелгән эшнең учетын алып бару тәртипкә салынмаган. Агитколлектив җитәкчеләре белән дә системалы эш алып барылмый. Агитаторларның көндәлек эшендә кирәк була торган материаллар—газета-журнал, китаплар, диаграмма, карта кебек күрсәтмә материаллар бер урынга тупланмаганнар, агитатор үзенә кирәк булган бу материалларны табу өчен күп вактын әрәм итәргә мәҗбүр була, ә еш кына ул аларны бөтенләй таба алмый. Шулай ук, агитаторлар өчен консультацияләр оештыру мәсьәләсе дә юлга салынмаган, ә консультацияләр, тәҗрибәләрне уртаклашу киңәшмәләре агитаторларга зур ярдәм итәләр. Лушников, Смолко, Самонов, Хлопошин, Скумбина, Караваев, Аптрашитова, Гаврилов, Кудряшева кебек агитаторларның эш тәҗрибәләрен агитколлективларда тикшергәндә бу нәрсә башка иптәшләргә зур ярдәм иткән булыр иде. Чөнки бу иптәшләрнең эш тәҗрибәләрендә башкаларга үрнәк булырлык күрсәткечләр бар. Бу иптәшләр үзләренең агитаторлык эшләрен намус белән башкаралар, үзләренең идея-политик дәрәҗәләрен күтәрү өстендә туктаусыз эшлиләр, агитация-масса эшләрен производство бурычлары белән бәйләп алып баралар. Ләкин, аларның эш тәҗрибәләре популярләштерелми. Бу турыда башка агитаторлар бөтенләй диярлек белмиләр.

Сайлаулардан соң участкыларда агитация эшләренең бөтенләй диярлек туктатылуы, фабрикадагы эшчеләр, инженер-техниклар, хезмәткәрләр арасында да сизелерлек йомшаруы өчен партия оешмасы җаваплы. Партбюро тарафыннан бу мәсьәләгә конкрет җитәкчелек җитәрлек булмаган. Партия җыелышларында, бюро утырышларында агитация мәсьәләләре турында карарлар чыгарылса да, ул карарларның үтәлешләре тикшерелмәгән. Аннан соң, партбюро секретаре иптәш Дорофеев агитация-масса эшләрен бюро членнарыннан берсенә тапшырып, бу эш белән үзе шөгылләнмәгән, конкрет җитәкчелек итмәгән. Агитация-масса эшенә партбюро секретаре үзе турыдан-туры җитәкчелек итәргә, аның белән туктаусыз кызыксынырга тиешлеге бик ачык нәрсә.

Агитация-масса эшләрендә матбугатның роле чиксез зур икәнен сөйләп торасы да юк. Кинопленка фабрикасында рус һәм татар телләрендә күп тиражлы ике газета чыгарыла. Советларга сайлаулар кампаниясе вактында бу газеталар агитация-масса эшләрен яктыртуы буенча шактый эшләр эшләгәннәр. Агитколлективларның, аерым агитаторларның эшләре турында, тәҗрибәләрне уртаклашу буенча газеталар икесе дә системалы рәвештә яктыртып килгәннәр. Ләкин, кампания үтү белән ике газета да агитация-масса эшләрен яктыртуны бөтенләй диярлек туктатканнар. Фабрикада агитация-масса эшләренең йомшаруына, элекке сайлау участкыларында эшнең бөтенләй диярлек тукталып калуына бу хәл бик нык тәэсир иткән.

ВКП(б) ның Ленин райкомы да агитация-масса эшләренә җитәкчелекне Советларга сайлаулар кампаниясе үтү белән йомшарткан.

Кинопленка фабрикасында большевистик агитация эшләрен бүгенге көннең сорауларына җавап бирерлек итеп куяр өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Фабрикада зур гына санлы партия һәм комсомол оешмалары бар, күп санда инженер-техник работниклар эшлиләр. Аларның күпчелеге агитация-масса эшләрен үрнәк итеп алып барырлык партияле һәм партиясез большевиклар. Бу иптәшләрне оештырырга, аларга көндәлек эшләрендә конкрет ярдәм итәргә генә кирәк. Партия, комсомол, профсоюз оешмалары агитация-масса эшләрен яхшыртуда барлык чараларны күрергә, эшне тамрыннан үзгәртеп корырга тиешләр.

Г. Баязитов.

ЗУРЛАРНЫ УКЫТУ ЭШЕНӘ ОПЕРАТИВ ҖИТӘКЧЕЛЕК КИРӘК

Мамадыш районында зурларны укыту эше өзеклектә. Район мәгариф бүлегенең соңгы маглүматларына караганда, укый-яза белмәүчеләрнең 63,8 проценты, аз укый-яза белүчеләрнең 57 проценты гына укуга тартылган. Дәрескә йөреш начар, уртача алганда 40 проценттан артмый.

Кайбер авылларда зурларны укыту эше аеруча начар тора. Мондыйлардан Комазан, Дүсмәт, Урта Кирмән, Гришкино авылларын күрсәтергә мөмкин. Иске Комазан, Уразбахта, Арташ һ. б. авылларда зурларны укыту эше бөтенләй оештырылмаган.

Допризывникларны укыту эше тагын да начаррак тора. РОНО работниклары районда ничә допризывник укырга тиешлекне дә белмиләр.

Зурларны укыту эшенә билгеләнгән акча тулы файдаланылмый. Культармеецлар өчен методик кулланмалар алынмаган.

Бу җитешсезлекләр район оешмаларына билгеле, ләкин алар зурларны укыту эшен яхшырту чарасын күрмиләр. *Ногманов.*

* * *

Зурларны укыту буенча мехкомбинатның аерым предприятиеләре шактый уңышларга ирештеләр. 4 нче мех фабрикасында укый-яза белмәүчелек тулысынча бетерелде. Дистәләрчә эшчеләр зурлар мәктәпләрен тәмам итеп стахановчылар мәктәпләренә укырга керделәр. Ләкин тулаем алганда мехкомбинат күләмендә зурларны укыту эше канәгатьләнерлек дип булмый әле. 618 кеше зурлар мәктәпләрендә укырга тиеш булса, бүгенге көнгә 314 кеше генә укуга тартылган. 3 нче фабрикада аз белемле 189 кешедән 70 е генә мәктәпкә тартылган. Алар да дәрескә системалы рәвештә йөрмиләр, йөреш 57 проценттан артмый. 2 нче фабрикада да шундый ук җитешсезлекләр кабатлана. Утиль заводында аз белемле 20 кешенең берсе дә укуга тартылмаган.

Мехкомбинат җитәкчеләре зурларны укыту эшендә кискен борылыш ясарга тиешләр. Татарстанның XX еллыгына укый-яза белмәүчелекне тулысынча бетерү өчен бирәдә бөтен мөмкинлекләр бар.

А. Таһиров, Ә. Сәйдәшев.

ҺӘРБЕР БРИГАДАГА—ТӨГӘЛ ЭШ ПЛАНЫ

КЫЗЫЛ ЮЛ РАЙОНЫ, ИСКЕ ӨҖЕМ КОЛХОЗЫ, 4 НЧЕ КЫРЧЫЛЫК БРИГАДАСЫНЫҢ ЯЗГЫ КЫР ЭШЛӘРЕ ПЛАНЫ

Безнең бурыч

Ел саен 8 миллиард пот ашлык житештерүгә ирешергә кирәк! Сталинның өченче бишьеллык план буенча социалистик авыл хуҗалыгы алдына куелган төп бурыч әнә шул. Партия тарафыннан, бөек остазыбыз иптәш Сталин тарафыннан бирелгән бу сугышчан заданиене үтәүдә иң якыннан катнашу—һәрберебезнең мактаулы эше.

Бу эштә кырчылык бригадаларының һәм трактор бригадаларының катнашы аеруча күренекле урын тотарга тиеш һәм ул, һичшиксез, шулай булачак. Сталинград өлкәсе бригадирлары Гуров һәм Козленков иптәшләрнең инициативасы буенча башланган һәм хәзерге көндә бөтен илебезгә җәелеп киткән йөзпотчылар хәрәкәте моның шулай булачагын күрсәтә инде.

Безнең бригадабыз да үз өстенә конкрет йөкләмәләр алып, бу гүзәл хәрәкәткә кушылды. Хәзер без югары иген уңышы өчен көрәшнең иң җаваплы чорында—язгы кыр эшләренә керешү алдында торабыз.

Нык уйланып төзелгән план язгы кыр эшләрен уңышлы итеп башкаруда көчле этәргеч ул. Быел, алда әнә шундый зур бурычлар торган бер вакытта план итүнең әһәмияте аеруча зур. Без язгы кыр эшләренә алдан ук игътибар бирәбез. Чөнки планлы эшләмәү, ул—сукыр килеш эшләү белән бер.

Бригаданың язгы кыр эшләре күләме һәм эш көчләре

Безнең бригадабыз быел 46,76 гектар сабан бодае, 40 гектар арпа, 25 гектар солы, 2 гектар тары, 3 гектар карабодай, 12 гектар борчак, 2 гектар ясмык, 10 гектар вика (орлык өчен), 8,8 гектар житен, 15 гектар клевер чәчәргә, 3 гектар бәрәңге утыртырга тиеш. 74,2 гектар арышыбыз һәм үткән ел чәчкән 9 гектар үләнебез (клеверыбыз) бар.

Иртә культураларны чәчеп бетергәч то 55,9 гектар мәйданда пар сөрәчәкбез. Пар басуына, елның заданиене үтәү өчен тагын 1.067 йөк тирес чыгарасыбыз бар. Язгы барлык чәчү мәйданының (152,56 гектар) бары 75 гектарында тунга сөрелгән. Димәк, безнең 77,56 гектар язын сөрәчәкбез бар. Безнең колхоз шартларында тунга сөрелгән жирләрне дә шактый өлешен гадәттә яз көне кабат сөрергә туры килә. Чөнки бездә туфрак тыгызланучан (көлсемән туфрак). Быел да тунга сөрелгән жирләрнең 17 гектарын кабат сөрергә планлаштырдык. Тунга сөрелгән жирләрнең 30 гектарын трактор көче белән культивацияләп, 20 гектарын ат көче белән лущит итәбез.

Соңгы культураларда тары, карабодай һәм бәрәңге жирләрен, билгеле, кабат сөрергә кирәк. Житеннең 5 гектарын салам белән мульчировать итәбез һәм ужымнарның бөтенесен дә (74,2 гектар) тырмалыйбыз, 6 гектарын сыекча һәм кош тизәге белән тукландырачакбыз. Бәрәңге астына көл кертәчәкбез.

Кыскача әйткәндә, язгы чорда бригада тарафыннан башкарылачак эшнең күләме әнә шундый.

Бу эшләрне башкару өчен бригадада 16 ат, бер жигүле тракторы, 12 ир, 25 хатын-кыз бар. Бригадада 13 рәтле бер чәчү машинасы, ике тәрәнле 8 сабан, бер тәрәнле 3 сабан, 4 культиватор, 20 данә тырма бар.

66,5 гектар мәйданда язгы сөрү, тунга сөрелгән жирләрнең 30 гектарын культивацияләү һәм иртә культураларның 96,5 гектарын чәчү тракторлар белән башкарылачак. Быел пар жирләренең бөтенесен дә (55,9 гектар) трактор көче белән сөрәчәкбез. Бу эш иртә культураларны чәчеп бетергәч, соңгы культураларны чәчү белән бер үк вакытта алып барылачак. Шулай итеп, пар сөрү 6,5 көн эчендә төгәлләнәчәк.

Гектарыннан йөз пот уңыш өчен

Колхозның производство планын төзегән вакытта без иген уңышы мәсьәләсе буенча колхозчылар белән киңәшеп һәрбер участок һәм һәрбер культура турында аерым сүз алып бардык һәм шуннан чыгып эш иттек. Мәсәлән, 5 нче басуның 20 нче клеткасындагы арыш (25,56 гектар) һәр гектарыннан 12,87 центнер, 4 нче басуның 13 нче клеткасындагы арыш (18,64 гектар) һәр гектардан 16,64 центнер уңыш бирергә тиеш. Бу 18,64 гектар арышчусында кар тоту чарасы үткәрелде. Шул ук вакытта бу 18,64 гектарның 6 гектарын тирес сыекчасы һәм кош тизәге белән тукландырачакбыз.

2 нче басу, 5 нче клеткадагы 25 гектар солы һәр гектардан уртача 17,33 центнер уңыш бирергә тиеш. Бу җирләр көзен яхшылап тунга сөрелгән иде. Бу клеткада кыш көне кар, ә яз көне кар сулары тоттык. Солыны бөтенесен дә шакмак ысул белән чәчәбез.

Башка культуралар өчен дә туфракның сыйфатын, сөрү катлавының тирәнлеген һәм үткәрелергә тиешле агрономия чараларын искә алып, культурасына карата уңыш алуны билгеләдек.

Быел 110 гектар мәйданда кар тоттык. Чәчү орлыкларын бик җентекләп тазарттык. Бодай, арпа, борчак, ясмык һәм тары культураларының орлыклары беренче категорияледәр. Бодай, арпа, солы, тары һәм бәрәңгене яровойлаштырып чәчәбез.

Колхоз безнең бригадага бөтен бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 91 пот иген уңышы алу өчен көрәшә. Бригада колхозчылар кимендә 100 пот иген уңышы алу өчен көрәшә. Монар тулы ышаныч бар. Чөнки 4 нче бригада элекеге елларда аерым участокларда 100 поттан артык иген уңышы алган иде. Мәсәлән, үткән ел икенче басу, бишенче клеткадагы көзге бодайның һәр гектарыннан (3 гектарда) 122 пот иген уңышы алдык. Шул ук клеткадагы 16 гектар мәйдандагы арыш һәр гектардан уртача 143 пот уңыш бирде. Бу, билгеле, кечкенә мәйданнар. Ләкин бер үк бригадада, барлык агрономия чараларын жиренә житкереп эшләгәндә зур мәйданнарда да шундый яхшы уңыш алырга була.

БРИГАДАБЫЗДА ЯЗГЫ КЫР ЭШЛӘРЕ ШУШЫ ТАБЛИЦАДА КҮРСӘТЕЛГӘНЧӘ ПЛАНЛАШТЫРЫЛА

№№	Эш төре	Үлчәү берәмлеге	Эшнең күләме	Эшләнәчәк: Тракторлар белән	Эшләнәчәк: Атлар белән	Бер көнгә эшләнәчәк: Тракторлар белән	Бер көнгә эшләнәчәк: Атлар белән	Ничә эш көнендә	Көн саен кирәк: Тракторлар	Көн саен кирәк: Атлар	Көн саен кирәк: Кеше
1	Кул белән клевер чәчү	га	15	—	—	—	—	1	—	1	7
2	Тунга сөрелгән жирләрне һәм үткән ел чәчелгән клеверны тырмалау	га	84	—	84	—	42	2	—	14	7
3	Ужым тукландыру	га	6	—	6	—	6	1	—	2	23
4	Ужым тырмалау	га	74,2	—	74,2	—	25	3	—	9	5
5	Язгы сөрү	га	66,5	66,5	—	13,5	—	5	1,5	1	5
6	Тунга сөрелгән жирләрне культивацияләү	га	30	30	—	30	—	1	1	—	2
7	Иртә культураларны чәчү	га	96,5	96,5	—	16	—	6	0,5	1	4
8	Кырга орлык ташу	центн.	154,4	—	154,4	—	28,8	5,5	—	1	1
9	Язгы сөрү	га	11	—	11	—	4	3	—	4	2
10	Яз сөрелгән жирне тырмалау	га	11	—	11	—	4	3	—	1,5	1,5
11	Тунга сөрелгән жирләрне лущить итү	га	20	—	20	—	6,7	3	—	6	3
12	Лущить ителгән жирләрне тырмалау	га	20	—	20	—	6,5	3	—	2	1
13	Тунга сөрелгән жирләрне кабат сөрү *)	га	17	—	17	—	—	5	—	—	3
14	Тунга сөрелгән жирләрне кабат сөргәннән соң тырмалау *)	га	17	—	17	—	—	5	—	—	1
15	Иртә культураларны чәчү	га	73**)	—	73	—	11,7	6	—	3	3
16	Пар сөрү	га	55,9	55,9	—	8,4	—	6,5	1	1	3
17	Парга тирес чыгару	йөк	1067	—	1067	—	180	6	—	12	24
18	Бәрәңге астына көл кертү	га	3	—	—	—	3	1	—	1	2
19	Соңгы культуралар өчен кабат сөрү	га	8	—	8	—	4	2	—	4	2
20	Соңгы культуралар өчен кабат сөрелгән жирләрне тырмалау	га	8	—	8	—	4	2	—	2	1
21	Соңгы культураларны чәчү	га	5	—	5	—	5	0,5	—	2	2
22	Бәрәңге утырту	га	3	—	3	—	3	1	—	6	27
23	Кырга бәрәңге ташу	центн.	48	—	48	—	48	1	—	1	8
24	Житенне мульчировать итү	га	5	—	—	—	2,5	2	—	2	15

Искәрмә: *) Тунга сөрелгән жирне ат көче белән кабат сөрүдә беренче 3 көнне бер пар ат, 4 нче һәм 5 нче көннәрдә дүрт ат эшли. Шул ук жирләрне тырмалауда беренче өч көндә бер пар ат, 4 нче һәм 5 нче көндә 3 ат эшли.

**) Бу сан асылда 48 гектар. 25 гектары солыны шакмаклап чәчү исәбенә арта.

Димәк, бу план буенча быел безнең бригадабызда тунга сөрелгән жирләрне тырмалау эше 2 көндә, ужым тырмалау 3 көндә, иртә культураларны чәчү 6 көндә, башка елларда гадәттә кимендә 15 көнгә сузылган пар сөрү 6,5 көндә төгәлләнәчәк. Төп эш тармакларындагы эш нормалары турында бер ике сүз. Без быел пар ат белән язгы сөрү нормасын 2 гектар итеп, машина белән чәчүдә һәр сошникка 0,9 гектар итеп, тырмалауда пар атка (ике эздән) 6 гектар итеп алдык.

Бригадада 4 даими звено бар. Шуларның 3 се даими гади звенолар, берсе ефремовчы звено. Һәр звенога 10—11 кеше беркеттек. Ефремовчы звенода 5 кеше эшли. Һәр звенога уртача 5 төрле культура туры килә. Мәсәлән, 2 нче звенога 28 гектар арыш, 38 гектар арпа, 3 гектар житен, 1 гектар бәрәңге, 9 гектар клевер беркеттек. Бригаданың югарыда күрсәтелгән язгы кыр эшләре планыннан чыгып һәрбер звено өчен дә язгы кыр эшләре планнары төзедек.

Без һич шиксез язгы кыр эшләрен планыбызда күрсәтелгән срокта үти алачакбыз. Монда тагын шуны әйтергә кирәк, бу планны уңышлы үтәвебез безгә хезмәт күрсәтүче Кызыл Юл МТС ының да ничек эшләвенә бәйләнгән. МТС работниклары быел үткән елгы кимчелекләрне кабатламаслар, тракторлар эше буенча билгеләнгән планны тулысынча үтәүне тәэмин итәрләр дип ышанабыз.

Бригадир ВӘЛИЕВ.

Бригада членнары ЖАББАРОВА.

ЖАМАЛИЕВА.

Колхозның агротехнигы ЖАББАРОВ.

Юдино районы, „Яңа тормыш“ колхозы председателе Х. Вәлиев һәм бригадир В. Чиляков иптәшләр звено башлыклары—С. Миңлебаева, З. Леңева һәм М. Хөснеттинова иптәшләргә язгы чәчү планы буенча кайсы звено кайсы кырда эшләячәк турында аңлаталар. И. Галиев фотосы.

Агрономия киңәшләре

Бәрәңгене яровойлаштыру

Яровойлаштыру—иң әһәмиятле агрономия чараларыннан берсе. Яровойлаштырып чәчелгән орлык тизрәк тишелеп чыга һәм бәрәңге тизрәк өлгерә. Яровойлаштыру уңышны да күтәрә. Моның шулай икәнлеге фән белән исбат ителгән һәм практикада күп тапкыр сыналган инде.

Бәрәңгене массовый күләмдә яровойлаштыру вакты килеп житте. Ләкин республикабыздагы колхозларның күпчелеге бу гаять әһәмиятле эшкә әле һаман да керешкәннәре юк. Мәсәлән, Лаеш районының „Победитель“, „Путь Ленина“, „Красный Знаменец“ колхозлары бәрәңгене яровойлаштыру өчен хәтта бина да хәзерләгәннәре юк. Мондый колхозлар башка районнарда да бар.

Яровойлаштыру эшенә мондый игтибарсыз карашны кичекмәстән бетерергә кирәк. Бәрәңгене яровойлаштыру планының арттырып үтәлүен тәэмин итү өчен тырышырга кирәк.

Бәрәңге ничек яровойлаштырыла соң? Аны берничә метод белән яровойлаштырырга мөмкин. Ул методларның берсе—бәрәңгене якты бинада, 12—15 градус жылылыкта, 30—40 көн срокта яровойлаштыру. Бу метод белән яровойлаштырганда бәрәңгеләрне рәшәткәле ящикләргә, яки рәшәткәле итеп эшләнгән киштәләргә 2—3 кат итеп тезеп куялар.

Яровойлаштыруның беренче чорында (10 көн чамасы) бәрәңгеләр шытым бирмиләр. Бу чорда яктылык булмаса да ярый. Шуңар күрә бу чорда салыну катлавының 30—40 сантиметрга кадәр булуы мөмкин. Ә 10—15 көн үткәннән соң бәрәңгеләргә яктылык бирергә кирәк. Моның өчен аларны югарыда күрсәтелгәнчә икеөч кат итеп тезеп салырга кирәк.

Икенче метод—бәрәңгене дым белән яровойлаштыру. Моның өчен бәрәңгене кәрзиннәргә яисә рәшәткәле ящикләргә салалар. Арага аерым катлау итеп (3—5 катлауга кадәр) чылатылган торф яки пычкы чүбе салалар. Торф яки пычкы чүбе катлауларының калынлыгы 2—3 сантиметр булырга тиеш. Торф яисә пычкы чүбен кипкән саен чылаткалап торырга кирәк. Бу метод белән яровойлаштыру 15—20 градус жылылыкта 15—20 көнгә бара.

Утырту алдыннан бәрәңгеләрне шиндерүне дә киң күләмдә кулланырга кирәк. Шиндерү бәрәңгенең тишелеп чыгу срогын кыскарта. Бәрәңге 10 һәм аннан югарырак жылылыкта 5—15 көн срокта шиңә.

Яровойлаштыру дөрес үткәрелсә генә тиешле нитиҗәне бирә. Бәрәңге яровойлаштырыла торган бинада әлбәттә вентиляция булырга, бинадагы температура көн саен үлчәнергә һәм температураның тиешле дәрәҗәдән артык күтәрелүенә дә һәм түбәнәюенә дә юл куелмаска тиеш. Чери башлаган бәрәңгеләрне алып ташлый барырга кирәк.

М. Галимов.

Татнаркомзем агрономы.

БОЗ КИТКӘНДӘ

(Татарстанның XX еллыгына карата язылган „Күперде“ исемле повестьтан өземтә)

Хәкимә Мишә буена караган ян тәрәзә аркылы кичтән су тавышын тыңлап утырды. Кинәт, Мишәнең теге ягыннан кичке салкын белән кемнендер кычкырганы ишетелде:

— Һәййй, көймә бирегез, көймә!

Бу, көч-хәл белән чана сөйрәтеп, Мишәнең аргы ягына кайтып туктаган почтальон Хәйрулла иде.

Яп-якты булып жәелгән су уртасында күпер саклаучылар тавышны бу як ярда торучыларга житкерделәр:

— Хәйрулла абзый көймә сорый, көймәәә!—дип кычкырдылар.

Шул арада яр буенда торучы берничә кешенең бик тиз генә көймәгә утырып, аргы якка таба кузгалганлыклары күренде. Хәкимә ишек алдына чыккан иде. Ул әлеге кычкырган кешенең Хәйрулла агай икәнлеген белү белән, яңадан өйгә кереп, өстенә җиңел җиләнен генә салды да, шунда ук,—Хисмәт кайтып төшмәде микән,—дигән уй белән Мишә буена йөгерде. Ул Хисмәтне, колхозның ун еллык бәйрәменә кайтыр, дип күптәннән бирле көтә иде.

Ярда почтальон Хәйрулланың бу якка чыкканын шактый вакыт көтәргә туры килде. Элек бу яктан көймә белән ташу ярып кереп китүчеләр Мишәнең үзәгенә житкәч, куркыныч алдында калдылар. Мишә байтак вакыт көймәне үзенең көчле дулкыннары өстендә бөтереп, аны йомычка кебек хәлдә тотты. Ишүчеләргә бик күп көч салырга туры килде. Алар Мишәнең үзәген үтә алмыйча байтак жир су агымы белән барырга мәжбүр булдылар. Шулай да бик тырышлык белән булса да аргы якка чыга алдылар. Әмма бу якка борылып, үзәккә житәбез дигәндә генә икенче бер зур куркыныч туды—кинәт мылтык тавышы ишетелде. Шуның артыннан ук күпер саклаучылар кычкырып жибәрделәр:

— Кире борылыгыз, кире, харап буласыз, боз килә, боз!

Мылтыкны кабат аттылар. Күпердән яңадан кычкырдылар:

— Боз килә, боз! Агымга кергәнче борылып калыгыз, борылып, харап буласыз, харап!

Шул арада ук мылтыктан өченче тапкыр залп белән аттылар.

Күпердә дә һәм көймәдә дә шау-шу башланды, чөнки бу, залп белән ату бик шомлы хәбәр иде.

Мишәнең ничә еллардан бирле килә торган усал бер гадәте бар. Көздән боз калын катып калган мондый елларда ул һичбер көч белән хисаплашмыйча, тирә-яктагы бөтен күперләрне алып китә, буе-буе белән ындыр читәннәрен суыра, печән кибәннәрен агыза, үзенә каршы торган бөтен көчләрне җимереп, зир-зәбәр китерә, каршы торган саен үзенең дәһшәтен арттыра, астындагы ташларны актарып, очраган тегермәннәрне куптарып килә. Аның мондый куркыныч белән ташуы илгә зур зиян китерә, ул мондый елларда күп корбаннар сорый. Ике-өч көн эчендә Мишә юкка чыгарган күперләрне, тегермәннәрне, бураларны яңадан төзекләндерү өчен, ул казып киткән юлларны тигезләү өчен, ул җимереп үткән читәннәрне яңадан торгызу өчен айлар буе җафаланырга туры килә. Бу исә җирле халык өчен бик күп мәшәкатьләр тудыра. Шуның өчен дә Мишә буена утырган авыллар аның дәһшәтенә каршы тору өчен, бергәләп алдан хәзерлек күрәләр, аның дәһшәтенә дучар булмау өчен авыллар үзара бер-бере белән хәбәрләшеп торалар. Мишәнең нинди көч белән, кайчан һәм ничек кузгалачагын кыштан ук бергәләп күзәтеп киләләр. Аның күп булса ике тәүлек, ә кайбер елларда бер тәүлектән дә артык дәвам итми торган бу котырынуыннан җәбер-җафасыз калу өчен, һәрбер авыл күперләрнең өстен алдан сүтеп, анда тәүлек буе сакчылар тота. Бу зур эш авылның иң батыр, гайрәтле ирләренә тапшырыла. Алар Мишәнең һәрбер хәрәкәтен җентекләп тикшереп торалар.

Әгәр дә ул калын бозларын ялык-йолык әйләндереп килә башласа, сак булыгыз, куркыныч бар, дигән мәгънәдә алдагы авылның күпер сакчыларына бер тапкыр мылтыктан атып хәбәр бирәләр.

Әгәр дә Мишә үзенең күкрәгенә киң бозлар салып, артык шауламыйча гына килә башласа, мылтыктан ике тапкыр аталар. Бу исә Мишәнең усал ерткыч шикелле тавышсыз-тынсыз гына килеп, кинәт, күпер свайларына һөҗүм итү турындагы хәбәр була. Ул мондый вакытта киң боз катлавы белән аерым свайларга гына кагылып калмый, ә бөтен күпернең астына керә һәм вактында аңа каршы чара күрә алмасаң, бик тиз арада күперне үз өстенә алып та китә. Мондый вакытта сакчылар бу киң бозларның килүен алдан белсәләр, озын жирдалар белән аларны күпердән читкә этәләр һәм бу бозлар гайрәтле, ләкин акылсыз ерткыч кебек күперне һичбер төрле һөҗүмсез-нисез генә әйләнеп киткәнлекләрен үзләре дә сизми калалар. Мондый бозлар килгәнне күргәч, сакчылар мылтыктан залп белән өч тапкыр аталар.

Кайбер елларда Мишә озак хәзерләнгән дошман кебек кузгала. Берсеннән-берсе калын һәм берсеннән-берсе зур, киң бозлар белән килә. Мондый вакытта жирдалар белән этеп кенә аның юлын яңлыштырып булмый, ул бер-бер артлы гаскәр кереп торган фронт төсен ала. Бер бозны этеп җибәрдем дигәндә генә икенчесе килеп җитә, икенчесен этеп җибәргәндә өченчесе килеп өлгерә, өченчесе артыннан дүртенчесе, аның артыннан бишенчесе килә. Бу хәл сакчыларны зур куркынычка төшерә. Һәм алар шушы зур көрәш эчендә алдагы авылның күпер сакчыларына залп белән атып кына калмыйлар, ә шул усал бозларның берсе өстенә ут ягып та озаталар.

Мылтыктан болай берьюлы өч тапкыр ату ул,—артык зур куркыныч барлык турында алдан сиздереп кую булса, боз өстенә ут ягып җибәрү исә,—дошманның ниндиерәк хәрәкәт белән, кайсы яккарак юл тотып килүен күрсәтү өчен эшләнә. Менә, ут ягылган зур боз якынайганнан якыная. Ул, калын урманнарны изеп аркылы чыгып бара торган танк шикелле юлда очраган барлык бүрәнә кисәкләрен үзенең астына йотып, туп-туры күпергә таба омтыла. Ләкин күпергә килеп җитәр алдыннан гына биш-алты урыннан аны жирдалар белән этеп җибәрәләр. Дәһшәтле боз катлавы шушы кечкенә хәйлә аркасында үзенең көчен югалта—бөтен гәүдәсе белән борылып, күпернең бер кырыннан үтеп китә. Аның артыннан берсе өстенә берсе менәрдәй булып тагы берничә боз кисәге килә.

Сакчылар яшен тизлеге белән кулларына жирдалар алып, Мишәгә каршы борылалар. Анда, өстендәге аппак карлары да юылмаган, хәтта кыш көне сугым суйганда калган кан-сүл дә бетмәгән зур бозның бөтен Мишәне иңләп әкрен генә килүе күренә. Ул башта кечкенә отрядлар җибәреп дошманның көчен сынаган оста гаскәр башлыгы кебек әлек вак бозлар белән күпергә килеп бәрелә. Болар кайсы кая таралып беткәч, һичбер нәрсә белән хисаплашмыйча үзе якыная башлый. Һәм сакчылар аны жирдалар белән генә читкә борып җибәрә алмый калалар, ул күпер алдына килеп туктый. Ул шулай торса, ун-унбиш минуттан күпер китәчәк булганлыктан һәм аны хәзер жирдалар белән этеп кенә җиңеп булмаганлыктан, сакчылар икенче бер чара табалар. Алар башына кәтмән шикелле кәкере, ләкин бик авыр, үткен тимерләр беркетелгән озын саплы кораллар белән аны берничә жиреннән вату өчен һөҗүм башлыйлар. Алардан көмешче Хафиз дигән берәүсе Камай дигән икенче берәү белән бозга бәрүендә дәвам итә. Башкалар күпернең икенче кырында, Хафиз исә күпер төбендәрәк, әлеге Камай исемле ир уртасы бер кеше белән бергәләп бозны ярырга маташа. Шул арада:

— Коткарыгыз, коткарыгыз,—дигән тавыш ишетелә.

Сакчылар борылып карасалар, Камайның кулларын бутый-бутый су эчендә үлем белән тартышканлыгын күрәләр. Ул бозга ябыша-ябыша бер аска китә, бер өскә калка. Аның янында гына агарынып көмешче Хафиз басып тора, үзе ни бер сүз әйтми, ни бер нинди хәрәкәт ясамый, гүяки җинаят өстендә тотылган кеше кебек хәлдә тора.

Сакчылар шунда ук күпер төбенә җыелалар. Барсы да кычкырыша-кычкырыша Камайга жирдалар сузалар, су өстенә озын арканнар ыргыталар. Ләкин Мишә Камайны бирми, аны бер калкытып, бер батырып җафалый-җафалый да, мескеннең хәле тәмам беткәч, аска ала. Аннары үзе корбан тапкан ерткыч кош кебек гел бер урында гына бөтерелә башлый. Сакчылар шунда ук ярда торучыларга кеше батканлык турында хәбәр бирәләр.

Яр буе бик тиз халык белән тула. Һәм үзенә корбан алган Мишә тынычлап калгандай була. Артык зур боз кисәкләре инде үтеп беткәнгә һәм күпер дә китми калганга күрә берничә кеше тыкрык эченнән бер зур көймәне сөйрәп суга төшерәләр дә, әчкә күпер янына кереп китәләр.

Барсы дүрт-биш көймә белән егерме-утыз кеше Мишәне актаралар, озын багурлар белән аның төбен айкыйлар, хәтта аның әллә кайдан, ерактан ук суыра торган урыннарына кереп тартышалар. Ничаклы гына тырышсалар да Камайның гәүдәсен таба алмыйлар.

Озак та үтми, ике таза егет утырган көймә белән Камайның хатыны Нәфисә күпергә килеп җитә. Көймә туктар-туктамастан үзен-үзе онытып, аз гына суга сикерми кала. Аның күзләре атылып чыгардай булып зурайган, тавышы карлыккан, гәүдәсе калтырый, үзе дивана кеше кебек һаман бер сүзне кабатлый:

— Нишләп батты ул, кайсыгыз күрде, нишләп батты ул?—ди.

Нәфисә башын кая куярга белмичә, әле берәүгә, әле икенчегә килеп бәрелә. Сакчыларның тыюларына карамастан, көймәгә утырып, Мишә белән үзе тартышырга маташа...

Хатын Мишәгә карап торган саен ярсый бара, вакыт-вакыт һушеннан яза, йөзе бума хастасы булган кеше төсен ала. Аннары тагы әче тавыш белән кычкырып җибәрә:

— Нишләп батты ул, кайсыгыз күрде?—ди.—Күпергә кайчан гына килеп өлгерде соң ул. Ул бит моннан бер сәгать чамасы элек кенә көмешче Хафиз белән үзебездә утырды. Безнекенең башы кызмача иде, ә Хафизда артык нәрсә күренми иде. Өйдән чыкма дип телемне әйләндереп әйтә алмадым, күңелемә ниндидер курку килгән иде югыйсә. Ул монда кем белән чыкты соң?—ди. Шул вакытта аның күзе, агарынып түбән карап торган көмешче Хафизга төшә. Нәфисә айнып китеп кинәт аннан сорый куя:

— Ә син монда нигә чыктың. Әллә Камайны да син алып чыктыңмы?

Аптырап калган Хафиз үзен юаш тота:

— Бергә чыктык инде без Нәфисә, аның болай булачагын кем белгән, белсәк, чыкмаган булыр идек тә бит, нишлисең, ул үзе: „Әйдә күпергә барыйк, боз киткәнне карап калыйк“, диде. Мин каршы килмәдем, Габдуллаҗан абзыйның көймәсен алдык та чыктык, ди.

Шунда ук сакчылардан Саттар исемле берәүсе Хафизга тутырып карый да, нәрсәнедер дөресләтергә теләгәнсыман кискен рәвештә сорый:

— Син Камай белән аның өендә бергә утырдыңмы?—ди.

— Әйе, бергә утырдым, аннары монда бергә чыктык,—дигән җавапны алгач, Саттар Хафизга яңадан ачу белән күзен тагы да тутырып карый:

— Ул батканда син нәрсә карап тордың соң. Без ичмасам аның янында түгел идек, ә син гел аның белән бергә булдың, өстәвенә аны һаман әйдәп тордың?—ди.

Бу җаваплашуның төбендә башта ук нәрсәдер бардыр кебек тоела, ләкин моны берәү дә ачык әйтә алмый иде.

Күпер өстендә шулай бераз әйткәләшеп алгач, Нәфисәне кайтарып җибәрергә булдылар.

Алар артыннан ук бая Мишәнең теге ягына килеп орынган көймә дә бу як ярга чыкты. Монда почтальон Хәйрулла белән читтән эштән кайтучы бер яшь егеттән башка кеше юк иде.

Донбасс ягында эшләүче ире Хисмәтнең кайтып төшүен көтүче Хәкимә халык арасында иде. Башында бик күп исәп бергә җыелган иде. Көймәдә Хәйрулла агай янында Хисмәт юклыкны күргәч бер кәефсезләнде, Нәфисәнең өч-дүрт бала белән Камайдан калуын уйлап икенче кәефсезләнде, өстәвенә тыкрыктан Мишә буена төшкән чакта көмешче Хафиз белән Камай арасында ниндидер бәхәс булганлыкны ишетеп калган иде. Камай Хафиздан: „Син тау буенда нишләп йөрдең“, дип сорый. Тегесе: „Әти зиратына менгән идем“ дип җавап кайтара. Камай аның саен ышанмый һәм: „караңгы төшкәч зиратта нишләп йөрмәк кирәк инде“ дип җаваплаша, кызган башы белән һаман шушы мәсьәләне кабатлый, әйләндерә дә бер сүзне әйтә, әйләндерә дә бер сүзне әйтә иде. Менә шулай әле бүген кич кенә күп булса моннан ярты сәгать, бер сәгать элек кенә тыкрыктан сөйләшеп үткән бу ике кешенең берсе—Камайны Мишә алган...

Бу хәл Хәкимәнең башына, ничектер, сыймый, ул аптырый иде.

Гариф Галеев.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 4 апрель. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе иглан иткән сводкада болай диелә:

„Көнбатышта берничә һөҗүмчел разведка вакыйгалары булды. 3 нче апрельдә төнлә белән Төньяк диңгездә һәм Англиянең көнчыгыш ярлары янында Германия самолетлары Англиянең сугыш карабларына һәм конвой сакчылыгында баручы корабль сәүдә карабларына атака ясадылар. Һавада Англия истребительләре белән берничә тапкыр бәрелешүгә, һәрби һәм сәүдә караблардагы зенит орудиеләренең көчле рәвештә атуларына карамастан, Германия авиациясенең атакалары уңышлы үтте. Бер эсминецка, ике сакчылык карабына һәм 5 сәүдә пароходына зур зиян килде. 3 сакчылык карабы һәм 1 сәүдә пароходы бомбардировка нәтиҗәсендә чыккан янгыннан янды. Германиянең 2 самолеты төшәргә мәҗбүр булды. Экипажлар коткарылды. Германиянең 1 самолеты үз базасына кайтмады. Һава сугышында Англиянең бер самолеты бәреп төшерелде.

БЕРЛИН, 4 апрель. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германия армиясенең баш командующие генерал Браухич 31 нче мартта инспекция максатлары белән фронтка килгән һәм берничә чиратта Рейндагы гаскәрләр янында булган. Генерал Браухич 4 нче апрельгә кадәр фронтта калган һәм штабка кайткан.

ПАРИЖ, 4 апрель. (ТАСС). Кичә кич иглан ителгән белдерүдә болай әйтелә: „Көнбатыш фронтта көн тыныч үтте. Төнлә дошман Франция постларының берсенә каршы һөҗүм итәргә маташты, ләкин уңышсыз чыкты. Берничә кешене пленгә алдылар“.

Бүгенге иртәнге белдерүдә болай диелгән: „Блис елгасы белән Вогезы арасында алгы частьләрнең активлыгы сизелә. Французлар немецларның берничә патрулен чигенергә мәҗбүр иттеләр“.

ГЕРМАНИЯГӘ АНГЛИЯ БЛОКАДАСЫНЫҢ КӨЧӘЮЕ

ЛОНДОН, 4 апрель. (ТАСС). Англиянең күп кенә газеталары Англия сугыш карабларының Адриатика диңгезендә Көньяк Славиядән Италиягә Германия өчен боксит төяп бара торган 3 пароходын тотканлыклары турында Белградтан хәбәрләр басып чыгаралар. Газеталарның язуына караганда, Лондонда бу хәбәрләр расланмый.

„Таймс“ газетасының язуына караганда, үткән елларда Көньяк Славия портлары аркылы ел саен 250 мең тонна чамасы боксит чыгарылган. Добровник порты аркылы бакыр, марганец, а Сушак порты аркылы—каракургашны рудасы чыгарылган. Сугышка кадәр бу портлар аркылы Германиягә агач та чыгарганнар. Газеталарның язуына караганда, Германия бик кирәк булган бу материалларны хәзер Италия аркылы кертергә мөмкин.

„Дейли телеграф энд Морнинг пост“ газетасының дипломатия күзәтүчесенең хәбәр итүенә караганда, якын вакыт эчендә Англия хөкүмәте махсус оешма төзячәк. Бу оешма товар алмашу нигезендә яки Кларинг системасы буенча Балкан илләре белән сәүдә эшен алып барачак. Англия бу илләрдән Англиянең аларның продукциясенә алмашка нефть, фураж, металлар һәм башка товарлар сатып алачак.

Радикал-социалистлар партиясендә Рейно хөкүмәтенә карата оппозиция

ПАРИЖ, 4 апрель. (ТАСС). Политик даирәләрдә радикал-социалистлар партиясенең хөкүмәткә каршы уңае белән Рейно хөкүмәте өчен туган кыенлыкларга игътибар бирелә. 2 нче апрельдә радикал-социалистлар партиясенең парламент группасы депутатлар палатасында 22 нче мартта булган тавыш бирү нәтиҗәләрен тикшерде. Кайбер депутатлар үзләренең хөкүмәткә каршы тавыш бирүләренең сәбәпләрен аңлатып сөйләделәр. Депутат Изоренен фикеренчә, киләчәктә радикал-социалистлар группасы хәзерге министрлар кабинетына карата хәрәкәт иреклеген сакларга тиеш, чөнки хөкүмәттә радикал-социалистлар партиясе членнары житәкчелек итми һәм шулай ук радикал-социалист министрлар хөкүмәтнең составына рәсми директиваларга алмыйча керделәр. Группа җыелышы делегация билгеләде. Бу делегация радикал-социалистларның парламент группасы җыелышында нәрсәләр сөйләнгәнлеген белдерү өчен Даладье янына китте. „Попюлер“ның язуына караганда, Даладье „радикаллар оппозициясенең акылларык булуы“ турында, үзенең позициясен лойяль төстә бергәләп эшләү турында радикал-социалист министрлар тарафыннан Поль Рейнога ясалган белдерүгә туры китерүләрен сораган“.

Франциянең коммунист депутатларына хөкем карары

БРЮССЕЛЬ, 4 апрель. (ТАСС). Кичә Парижда Франциянең 44 коммунист депутатының процессы тәмам булды. Шулардан 9 депутат үзләре югында хөкем ителделәр. Трибуналның иртәнге утырышында суд ябык рәвештә җыелып, хөкем карары чыгару алдыннан, гаепләнүчеләргә соңгы сүзне бирде. Гаепләнүчеләрнең берсе барсы исменнән сөйләде.

Гаепләнүчеләрдән 26 кеше һәр кайсы бишәр елга төрмәгә, 4 мең франк штрафка һәм 5 елга гражданлык һәм политик хокукларыннан мәхрум ителүгә хөкем ителделәр. Флоримон Бонт 5 елга төрмәгә, 5 мең франк штрафка һәм 5 елга гражданлык һәм политик хокукларыннан мәхрум ителүгә хөкем ителделәр. Үзләре югында хөкем ителгән депутатлар—Катла, Жак Дюкло, Дютейль, Монмуссо, Пери, Раметт, Ригаль, Торез һәм Гийон 5 елга төрмәгә, 5 мең франк штрафка һәм 5 елга гражданлык һәм политик хокукларыннан мәхрум ителүгә хөкем ителделәр.

Гаепләнүчеләрдән 8 кеше „гаепләрен йомшарта торган сәбәпләр булганлыктан“ 4 елга шартлы рәвештә төрмәгә, 4 мең франк штрафка һәм 5 елга гражданлык һәм политик хокукларыннан мәхрум ителүгә хөкем ителделәр.

КЫТАЙНЫҢ МИЛЛИ-ПОЛИТИК СОВЕТЫ СЕССИЯСЕ

ЧУНЦИН, 4 апрель. (ТАСС). 2 нче апрельдә Кытайның милли-политик советы сессиясе бер тавыштан кабул ителгән моражәгатне халыкка иглан итте. Мөраҗәгат җиңүгә кадәр көрәшне дәвам итәргә һәм „Ван Цзин-вейнең хиянәтчел эшен“ тамгаларга чакыра.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА. Суйюань провинциясендә, Уюань шәһәре тирәләре япон гаскәрләреннән чистартылды. Японнарның төп көчләре шоссе юлы буйлап Баотоуга чигенәләр. Бу районда сугышларның нәтиҗәләре японнарның февраль башларында башланган һөҗүменең җимерелүен күрсәтәләр.

КӨНЬЯК КЫТАЙДА. 3 нче апрельгә каршы төндә японнарның 300 кешелек отрядын Наньниннан көньяк-көнчыгыштарак, Сяодун районында кытай гаскәрләре чолгап алдылар һәм юк иттеләр.

Фуцзян провинциясендә. Амой якынында японнарның 3 авионосы, 87 сугыш карабы һәм 255 самолеты бар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА. Цзянсу провинциясенең үзәк өлешендә, Дацзунху күле районында японнар отряды Фаньшуй якынында партизаннарның позициясенә атака ясады. Партизаннар чигенергә мәҗбүр булдылар. Икенче көнне япон гаскәрләре отряды Хуайань районында партизаннарның позициясенә атака ясады. Озак сугышканнан соң японнар кысрыкландылар.

4 апрель.

РАФАЭЛЬ

Бүген, 6 нчы апрельдә Италиянең бөек художнигы Рафаэльнең үлүенә 420 ел тула. Рафаэль Урбино шәһәрендә туа. Аның атасы Джовани Санти шулай ук художник була. Ул дини эчтәлекле күп кенә картиналар яза.

Рафаэль бик яшь вактыннан ук художество белән кызыксына һәм зурларның игтибарын үзенә җәлеп итә. Ул шул заманның иң эре художникларыннан Перуджиногa өйрәнчек булып керә һәм бик тиз вакыт эчендә художниклык мастерлыгын үзләштерә.

21 яшендә Рафаэль провинция шәһәре Перуджиядан шау-шулы Флоренциягә күчеп килә. Монда ул бөек мастер Леонардо да-Винчи һәм Микель Анжело әсәрләрен өйрәнә.

Рафаэль бик тиз вакыт эчендә үзенең искиткеч таланты белән зур дан казана. 4 ел үткәннән соң (1508 нче елда) папа Юлей II аны Ватикан сарайларының стеналарын бизәү өчен чакырып ала. Рафаэльнең мастерлыгы монда чәчәк ата. Ватикан сарайларының стеналарына ясалган рәсемнәре ана дөнья күләмендә дан китерәләр.

Рафаэльдә гаять зур энергия була. Аның күп сандагы эшләре бөтен дөньяда билгеле. Аның тарафыннан стеналарга ясалган фрескалар, картиналар, гравера өчен ясалган рәсемнәр, мозаика, скульптуралар, зур эскизлар һәм башкалар аның гаять бай иҗады турында сөйлиләр. Аның иң зур һәм атаклы картиналарыннан „Сикстинская Мадонна“, „Преображение“, „Аполон һәм Муза“ һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Рафаэль Италия художествосының иң бөек, чәчәк ату чорында эшли. Аның иҗади күтәрелеш эпохосына туры килә. Аның иҗадында сюжетны идеаллаштыру һәм типажны идеаллаштыру характерлы момент булып тора. Шулай ук нәфис пластик рәсемнәр дә аның иҗады өчен характерлылар.

Рафаэль 1520 нче елда үзенең иҗады чәчәк аткан вакытта 37 яшендә үлә.

Г. Поляков.

ИНДИВИДУАЛЬ ТОРАК ЙОРТЛАРЫ

Ленин исемендәге күн заводы эшчеләре һәм хезмәткәрләре индивидуаль торак йортлары төзүгә 25 мең сум ссуда алганнар иде. Байтак эшчеләр һәм хезмәткәрләр үзләренә торак йортлары төзүне тәмам иттеләр. Дублау цехы стахановчысы Крупеницин, көлләү цехы стахановчысы Низаметтинов, завод карначы Муртазин, йөк ташучы Җиһаншин, охранник Горинов, көлләү цехы стахановчысы Васильев һәм башка иптәшләр үзләренә яңа йортлар төзеделәр.

МАЯКОВСКИЙ ТУРЫНДА ЛЕКЦИЯ

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты янындагы лекцияләр бюросы 10 нчы апрельдә Кызыл Армия йортында шагыйрь Маяковский турында лекция үткәрә. Маяковскийның тормышы һәм иҗады турындагы бу лекцияне Москвадан килгән лектор иптәш Шпендлер укыячак.

***

Менжинский исемендәге клуб 14 нче апрельдә — Маяковскийның үлүенә 10 ел тулу көнендә Маяковскийга багышланган әдәби кичә үткәрә. Кичәдә Маяковский турында доклад һәм художество бүлеге булачак.

МАЯКОВСКИЙГА БАГЫШЛАНГАН КҮРГӘЗМӘ

Татарстанның крайны өйрәнү үзәк музее Владимир Маяковскийга багышлап күргәзмә оештыра. Күргәзмәгә Маяковскийның Ватан, партия, комсомол һәм Ленин турындагы шигырьләре һәм чыгышларыннан өзекләр куела. Шунда ук Маяковский турында чыккан әдәбияттан витрина оештырыла.

ТАТАРСТАНДА

Татарстан колхозларында быел җил көче белән хәрәкәт итә торган 56 двигатель куела. Алар колхозларны су белән тәэмин итү, җимеш һәм яшелчә бакчаларын сугару өчен булган насосларны хәрәкәтләндерәчәкләр. Бу эшләрне оештыруга 368 мең сум кредит билгеләнде.

***

Быел җәйге сезонда Татпромсовет системасындагы артельләрдә эшләүче кустарьларның балаларыннан 550 кеше пионер лагерьларына чыгарыла. Аларның расходларына Татпромстрахкасса тарафыннан 162 мең сум акча җибәрелә.

***

Кукмара районының Яңиль МТС ы производстводан аермыйча хатын-кызлардан 22 тракторчы хәзерләде. Курсларны отличногa һәм яхшыга тәмам итүчеләр арасында Егорова, Мостафина, Юдина һәм Вәлиева иптәшләр бар. Курсларны тәмамлаучы кызлар барсы да трактор бригадаларына беркетелделәр һәм колхозларга практик эшкә киттеләр.

***

Тельман районының Карасa авылы аучысы—72 яшендәге Мәхмүт Әхмәдиев быел 3 бүре үтерде. Ул үз гомерендә барлыгы 142 бүре үтергән. Иптәш Әхмәдиев бүләкләнде.

***

Яңа Чишмә районының Зирекле авылы допризывникларыннан 21 кеше призывка хәзерлек буенча оборона значокларына нормалар тапшырдылар. Допризывниклардан 21 кеше „ГСО“, 18 кеше „ПВХО“ һәм 16 кеше „Ворошиловча атучы“ значогына нормалар тапшырдылар.

— Казан Кызыл Армия йорты 3 нче апрельдә русның бөек галиме Михаил Васильевич Ломаносовның тормышына һәм иҗадына багышлап доклад үткәрде. Доклад зур кызыксыну белән тыңланды.

ЕЛГАЛАРДА

5 нче апрельгә каршы бер тәүлек эчендә **Волга** суы Горький янында 21 сантиметр, Козьмодемьянский янында 28 сантиметр, Югары Ослан янында 34 сантиметр, Тәтеш янында 31 сантиметр артты. Югары Ослан янында арткан суның биеклеге 2 метр 45 сантиметр булды. Куйбышев янында боз кузгалды.

Кама суы соңгы бер тәүлек эчендә Молотов шәһәре янында 15 сантиметр, Алабуга янында 33 сантиметр, Чистай янында 35 сантиметр, Лаеш янында 44 сантиметр артты. Алабуга янында Кама аркылы җәяүлеләрнең һәм атлыларның чыгып йөрүләре туктатылды. Чистай янында Кама бозы күтәрелде.

Окада Белев, Калуга һәм Кашира янында боз ага. Бирски янында Агыйдел бозы кузгалды.

Казанка суы Арча янында 93 сантиметр, Казан янында 54 сантиметр, Мишә суы Рождествено янында 69 сантиметр артты. Зәй, Чишмә һәм Зөя елгаларында боз ага башлады.

ШӘҺӘР БЕРЕНЧЕЛЕГЕ ӨЧЕН ВОЛЕЙБОЛ ЯРЫШЛАРЫ

24 нче мартта республика комитетының спорт залында волейбол буенча Казан шәһәре беренчелегенә ярышлар башланган иде. Волейбол ярышлары дәвам итә. Ярышларда 7 спорт җәмгыятеннән барлыгы 35 команда (шуларның 14 е хатын-кызлар командалары) катнаша.

Дүрт очрашудан соң беренче урында „Азот“ (КХТИ) командасы бара. Бу команда ярышларда 156 очко җыйды. Икенче урында „Советлар Канаты“ (148 очко) командасы бара. Бу командаларның һәр икесе ярышларга яхшы хәзерләнгәннәр.

Ләкин начар хәзерләнгән командалар да бар. Мәсәлән, „Спартак“ җәмгыятенең командасы бу әһәмиятле очрашуларга тиешенчә бәя бирмәгән.

Ярышлар 12 нче апрельгә кадәр дәвам итәчәк.

БОКС ЯРЫШЛАРЫ

24 нче апрельдә республика комитетының спорт залында шәһәр боксерларының ярышлары башлана. Ярышларда „Динамо“, „Спартак“, Медицина институты, Казан Хәрби Пехота училищесе, Авиация институты һәм башкаларның көчле боксерлары катнашалар.

Бокс ярышлары 3 көн дәвам итәчәк.



Москваның Большая Полянка урамында тизләтелгән метод белән гаять зур торак йорты төзелә. Рәсемдә: йортның иң эре блокларын төзүнең барышы. С. Шагаль фотосы (ТАСС фото-клишесе).

„ТАНЯ“

(Татар Дәүләт Академия театрының яңа постановкасы)

А. Арбузовның артист Ильдар тарафыннан татарчага тәрҗемә ителгән „Таня“ исемле пьесасы бүгенге тормышыбыз яктысында семья һәм мәхәббәт мәсьәләләрен күтәрә.

Сигез картинага сузылган вакыйга әсәрне укыган чагында бик гади шикелле генә күренә. Ихтимал, бу тәэсир кайбер күренешләрнең артык булуларыннан, эпизодик рольләрдә чыгучыларның күплегеннән һәм гомумән, пьесаның яхшы драматургия әсәре булудан бигрәк, сәхнә өчен язылган очеркка якын торуыннан киләдер. Ләкин „Таня“ның баш режиссер Е. Г. Амантов тарафыннан вак детальләргә кадәр тулы эшләнелүе һәм Таня ролен халык артисткасы Фатыйма Ильскаяның гаять матур башкаруы бу постановканы театр тарихында эз калдырырлык иҗад вакыйгаларе дәрәҗәсенә күтәрәләр.

Яше белән 20 дән узган, бала күңелле Таня конструктор Германга кияүгә чыга. Ирен ул чиксез бер ярату белән ярата. Аның өчен ул җәмгыят тормышын да, үз интересларын да—бөтенесен дә оныта. Таня уйлавынча: „Мәхәббәт—үзеңне онытудан гыйбарәт“. Таня „син дә мин генә“ итеп яшәргә тели, хәтта семьяда бала тавышын да ишетергә теләми.

Таняның нигездә ялгыш булган бу кайнар мәхәббәтен Фатыйма Ильская бик матур бирә. Саф күңелле Таняның балаларча шаяруын, ягымлы „җүләрлеген“, сөюдән башка һич нәрсәне белергә теләмәвен күрсәтү өчен Ильская гаҗәп матур буяулар таба: тавышы белән бергә аның куллары да, аяклары да уйныйлар.

Мәхәббәтне ялгыш аңлаган, бала күңелле Таня мещанлыкка тәгәри. Аны кызгана башлыйсың. Сәхнәгә орденлы Шаманова һәм батыр йөрәкле аучы Соколов килеп кергәннән соң Таняны кызгану тойгысы тагын да үсә. Өйгә тормыш ямен алып килгән Соколов белән сөйләшкәндә Ильскаяның Танясы бөтенләй аптырап кала, аның йөзендә, калтыравыклы тавышында: „Эх, мин җүләр! укуымны юкка ташладым!“ дигән сызлануны күрәсең. „Мә, иреңә бүрек тегәрсең!“ дип, Соколов Таняга аучылар союзы җибәргән мехны калдырып китә. Мех аның уйларын мединститутка, практикада булган урыннарга алып китә. Бу турыда Таня бер сүз дә әйтми. Моны Ильскаяның мехны кая итәргә белмәвеннән, аптырап калуыннан, матур уйнавыннан гына сизәсең.

Ялган нигезгә корылган бу семья җимерелә. Герман Шамановага мәхәббәт иглан итә, ә шуны очраклы рәвештә тыңлап торган Таня чемоданын күтәреп бу тормышны ташлап өйдән чыгып китәргә мәҗбүр була. Таняның бу күренешләрдәге кичерешләрен Ильская зур осталык белән бирә. Аның уенында ялган хәрәкәт тә, Таня образын бозып җибәрә торган ясалма тавыш та юк. Бөтен нәрсә табигый. Менә ул басып тора, алып китәргә хәзерләнгән чемоданын бер ача, бер яба... Мехны да, Германның рәсмен дә чемоданга сала.. Моннан 15 кенә минут элек Таня Германга үзенең шатлыгын—балага узуын әйтергә теләгән иде, ләкин Герман аны тыңлый алмады. Ә хәзер чыгып китәргә, бөтенләй-гә китәргә... Күрше бүлмәдә Германның иптәшләре нәрсәгәдер кычкырып көләләр... Әнә, Шаманованы озатып Герман үзе дә кайтып керә. Аның белән очрамас өчен Таня гардеробка яшеренә. Ләкин барыбер очрашалар. Бөтенләйгә китә торган Таня, күз яшен йотып, дөресен әйтмәскә, тырыша,—„Портнихага барам“,—ди. Ә Герман уч иткәндәй,—миңа 3 сум 50 тиеннек папирос ала кайт,—ди.

Таня фаҗигасен шул кадәр оста, чын сәнгатчә ачып биргән Фатыйма Ильскаяның уенын тамашачылар озак онытмаслар һәм аны бу рольдә күргән иптәшләр тагын килеп карарлар.

Шушындый авыр кичерешләрдән соң да Таня Германны ятарудa дәвам итә. Ул бала китерә. Ләкин озакламый бала дифтерит белән авырый башлый—һәм үлә. Бу хәл Таняга бик авыр тәэсир итә.

Монда да Ильская Таняның тирән кичерешләрен аңлату өчен тамашачыны дулкынландырырлык сәнгат буяулары таба. Баланы үлемнән коткарып калу өчен Таня мединституттан калган дәфтәрләрен актара, ләкин дифтериттан балаларны ничек дәвалау лекциясе язылмый калган. Ул көнне Таня Герман белән Воробьев тавына барган... тагын Герман, тагын мәхәббәт. Димәк, бала да шуңа корбан итела. Таня болай яшәргә ярамаганлыкны аңлый. Ул яңадан укырга керә, институтны тәмам итеп, врач булып чыга һәм илебезнең ерак бер почмагына эшкә китә.

Яңа тормыш башлана, Таня кайнап торган тормышның эченә керә. Котырган буранда ул үз-үзен аямыйча чаңгыларда шуып авыруларга ярдәм итә. Яңадан батыр йөрәкле Соколов белән очраша.

Таня үлем хәлендә яткан бер баланы коткарырга бара. Бу бала Германның Шамановадан туган баласы булып чыга. Таня аны дәвалый, аңа үз баласына караган кебек тирән җылылык белән карый һәм шунда элекке ире Герман белән дә очраша.

Ильскаяның бу картинадагы оста уенын сөйләп бирү кыен. Ильская Танясында Германга карата ачу да юк, аны көнләшү дә юк, ниндидер бер матур үпкә генә бар. Таня элеккечә үк бала күңелле. Ләкин аның карашы үскән, ул күп кайгылар кичергән, тормыш аңа үзенең йогынтысын ясаган. Хәзер аңа җиңел, үзен ул бик иркен тота. Таняда яңа сыйфатлар арта һәм ул үзен хәзер Германнан өстенрәк хис итә. Ильскаяның 8 нче картинадагы Танясына 1 нче картинадагы Таняның матур „шуклыгы“ килеп кушыла. Һәм чын сәнгатчә уенга карап, тамашачылар зур ләззәт алалар, кешеләрне танырга өйрәнәләр.

Алданган мәхәббәт аркасында, җимерелгән семья нәтиҗәсендә үз-үзен югалткан, тормыштан артта калган Танялар юк түгел. Фатыйма Ильскаяның онтылмаслык Танясы бөек тормышта үзенең урнын таба, ул югалмый һәм бүтәннәрне дә мәхәббәт корбаны булмаска, югалмаска чакыра.

Безнең аңыбыздан иске карашлар чыгып беткәне юк әле. Татар театрының бу постановкасы һәм Ильскаяның Танясы безне шул иске карашлар белән көрәшергә, кешеләр белән нинди мөнәсәбәттә булырга өйрәтә.

Талантлы Ильскаяның Таняны матур итеп бирүен күрү белән бергә, бу спектакльдә башкаларны да, Таняга үсәргә булышкан аучы Соколовны да күрәбез, Таняның кайгысын да, шатлыгын да тагы да тулырак, тагы да ачыграк аңларга ярдәм иткән бүгенге тормышыбызны да күрәбез. Таня ялгыз түгел. Режиссер Е. Г. Амантовның зур уңышы бу, әлбәттә. Һәрбер образга ул үзенең буявын биреп, спектакльнең идеясен югары күтәрә алган.

Художник Сутюшев тарафыннан беренче, бишенче, алтынчы һәм сигезенче картиналар яхшы эшләнгәннәр. Әби өендәге картиналарда—анда Таня һәм Дуся торганны күрсәтерлек җыйнаклык юк. Ә клуб сәхнәсе артындагы картинада кирәге булмаган натурализм һәм шуннан туган кысынкылык начар тәэсир калдыра.

„Таня“да байтак артистлар катнашалар. Аларның күбесе (мәсәлән, Таждарова, Камал III, Булатова, Халитов, Сәгыйтов, Закиров һәм Надруков) Таня образын ачарга нык кына ярдәм итәләр. Соколов ролендә чыккан артист Зияттиновта сәхнә өчен кирәкле булган бик яхшы сыйфатлар бар. Ильскаяның Танясын ярату белән бер рәттән, тамашачы Зияттиновның Соколовын да яратты.

Спектакльнең соңгы пәрдәсе Таня белән Соколовның озын юлга чаңгыда чыгып китәргә хәзерләнүләре белән төшә. Тамашачы аларга бәхет тели һәм, һич шиксез, бу бәхетнең булуына, чәчәк атуына ышана.

Г. К.

Редактор урынбасары И. ҮЗБЕКОВ.
Зам. редактора И. УЗБЕКОВ.

19 нчы апрель, кич 7 сәгатьтә Терапевтика клиникасы факультеты аудиториясендә Казан Дәүләт Мединституты гыйлми советының ачык утырышы чакырыла һәм түбәндәге темаларда халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ

яклау үткәрелә:

1) Медицина фәннәре докторы дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен, доцент Б. С. Гинзбург. Тема: „Рахит авыруына карата антенаталь профилактика турында“.

Рәсми оппонентлар: профессор А. Ф. Агафонов, профессор В. К. Меньшиков һәм доцент Е. П. Кревер.

2. Медицина фәннәре кандидаты дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен, доцент В. К. Украинский. Тема: „Кул анатомиясенә карата материаллар“.

Рәсми оппонентлар: профессор В. Н. Терновский һәм доцент И. Н. Маточкин.

Диссертация материаллары белән Фәнни Медицина Җәмгыятьләре Советы китепханәсендә танышырга мөмкин.

587—1

ДОК та (Казан, Триумфальный урам, 2)

ТӨРЛЕ ЗУРЛЫКТА тәрәзә рамалары һәм ишекләр —САТЫЛА—

583—2—1

Галиәсгар Камал исемендәге **Татар Дәүләт Академия театры**

Бүген, 6 нчы апрельдә көндез һәм кич, шулай ук 7 һәм 8 нче апрельдә

ТАНЯ

Талоннар белән кертелми.

Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТГДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 6 нчы апрельдә көндез һәм 8 иде

МАСКАРАД

6 нчы апрельдә кич В. Шкваркин әсәре

КУРКЫНЫЧЛЫ СУД

Талоннар белән кертелми.

Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

7 нче апрельдә Зур театр бинасында

ФАУСТ

9 нчы апрельдә Татар Дәүләт Академия театры бинасында

ИРЕК

Талоннар белән кертелми.

Кич 8 сәгатьтә башлана.

Коллектив рәвештә килү өчен 29—94 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген һәм һәр көн 3 бүлектә

ЗУР ЦИРК УЕНЫ

ФРАНЦУЗЧА КӨРӘШ ЯРЫШЫ

ҺӘР КӨН 3 ПАР КӨРӘШӘ

Бүген, 6 нчы апрельдә зур программада

КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ

Уеннар көндез 12 дә, кич 8 дә башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 11 гә кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 10, 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Тавышлы, художестволы яңа фильм ЗУР ТОРМЫШ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, һәм 10 да.	ШАТЛЫК ЭЗЛӘГӘНДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8, 10 да.	ИСТРЕБИТЕЛЬЛӘР
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ДИҢГЕЗ ПОСТЫ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6-30, 8 һәм 10 да.	КАБАРДА АТЛЫСЫ Көндез 1 сәгатькә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	Тавышсыз фильм ҖИР ПЛЕНДӘ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	КЕЧКЕНӘ АНА
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	ТАШЛАНДЫК

КИРӘК:

„Органборнефть“ уполномоченнына, Татарстан республикасында эшләү өчен, ашыгыч рәвештә РАЙИНСПЕКТОРЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Киров урамы, 11, Элеваторстрой. Иртән 9 сәгатьтән көндез 4 кә кадәр иптәш Спиридоновка мөраҗәгат итәргә. 582—1

Казан Эпидемиология һәм Микробиология институтына даими эшкә КАРТОТЕКАЧЫ, ДИПЛОМЛЫ КОЧЕГАР һәм термостан, шулай ук автоклав эшләүдән белүче СЛЕСАРЬ. 575—3—1

Язу машиналары заводына, МЕТАЛЛНЫ МЕХАНИК ЭШКӘРТҮ МАСТЕРЛАРЫ, БАРЛЫК РАЗРЯД МЕТАЛЛ ЮНУЧЫЛАР, БАРЛЫК РАЗРЯД ТОКАРЬЛАР, ШУЛАЙ УК БАРЛЫК РАЗРЯД ФРЕЗЕРЧЫЛАР ҺӘМ СЛЕСАРЬЛАР.

Шунда ук, токарьлык фрезерчылык, автоматчылык, слесарьлык белгечлекләре һәм башка белгечлекләр буенча ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН 18 яштәге ирләрдән һәм хатын-кызлардан ГАДИ ЭШЧЕЛӘР. Казан, Ирек мәйданы, Язу машиналары заводы. Эшчеләр алу өстәленә килергә. 576—1

АВТОКУЗОВНЫЙ ЗАВОДКА (Эшчеләр бистәсе, Набережный урам, 11) БАШ МЕХАНИК, ФИНАНС БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, КАРТОТЕКАЧЫЛАР һәм 5—6 нчы РАЗРЯД КАЛАЙЧЫЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Заводның кадрлар бүлегенә килергә. 584—3—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 1358. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА. ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 1268.